ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНӘ ЭЛЕКТРОН КУШЫМТАЛАР

Методик ярдәмлек

КАЗАН
2015

**ББК 74.268.1Тат**
**Т23**

**Проект җитәкчеләре:**
**Р.Г. Хәмитов,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ректоры, педагогика фәннәре кандидаты, доцент
**Л.Ф. Салихова,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты укыту-методик эшләр буенча проректоры, педагогика фәннәре кандидаты

**Рецензент:**
**Хуснутдинов Д.Х.,** филология фәннәре кандидаты, КФУ Татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты

**Төзүчеләр:**
**Шәмсетдинова Р.Р.,** татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире
**Башарова А.А.,** КФ(П)У татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы магистры

Татар теле дәреслекләренә электрон кушымталар: методик ярдәмлек. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 68 б.

Монографик әсбап татар телен өйрәнү өчен төзелгән электрон кушымталарның теоретик һәм гамәли мәсьәләләрен өйрәнүгә багышлана. Анда электрон кушымталарны эффектив куллану өчен мөһим мәгълүмати компонентларны аерып чыгарыла. Электрон кушымталар һәм электрон ресурслар, аларны төзү, алардан урынлы һәм нәтиҗәле файдалана белү заман таләбе. Кулланма укытучыга шул таләпләрне тормышка ашыруда ярдәмче кулланма буларак язылды, татар теле һәм әдәбияты укытучыларына тәкъдим ителә

© ГАОУ ДПО ИРО РТ, 2015

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш ........................................ 4

1. Электрон кушымталар һәм аларның укыту процессындагы роле ....... 5

2. Тел һәм әдәбият дәресләрендә электрон кушымталарны куллану ... 17

3. Мәктәп дәреслекләренә электрон кушымталар ........................ 34

3.1 Программа өлеше ........................................ 34

3.2 Структура ........................................ 39

3.3. Биремнәр ........................................ 43

3.4 Медиафайллар ........................................ 51

4. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда заманча технологияләр кулануның әһәмияте ........................................ 55

Файдаланган чыганаклар һәм әдәбият исемлеге ........................ 58

## КЕРЕШ

Информатизация, мәгълүмати технологияләр тормышыбызның күп кенә өлкәләренә, шул исәптән мәгарифкә дә көчле йогынты ясый. Мәгариф системасын модернизацияләү бурычын тормышка ашыруда мөмкин булган юлларның берсе – традицион укыту чараларын заманча мәгълүмати һәм компьютер технологияләре белән берлектә куллану. Мәгълүмати һәм компьютер технологияләрен куллану укучы шәхесен формалаштыру, вариативлык, мәктәп программасын индивидуальләштерүдә ярдәм итә. Шулай ук өйрәнелә торган предметны актив һәм иҗади үзләштерүдә мөһим роль уйный, материалны яңа югарылыкта аңлату, укыту процессын заман таләпләренә туры китереп оештыруда яңа мөмкинлекләр ача. Россиядә мәгариф системасы үзгәрешләр кичерә, инде дүртенче буын федераль дәүләт белем стандартлары (ФГОС) эшләнелә. Россия Федерациясенең «Мәгариф турында»-гы канунында [Об образовании в Российской Федерации: федер. закон от 29 декабря 2012 г.] электрон ресурсларга аерым игътибар бирелүен күрәбез. Укыту программаларын тормышка ашыруда куллануга тәкъдим ителгән дәреслекләрнең 2014-2015 елда кабул ителгән федераль исемлегенә дә һәр дәреслек электрон кушымтасы белән кертелгән, чөнки әлеге исемлеккә керү өчен бу мәҗбүри таләп булып тора. 2015 елдан башлап, дәреслекнең электрон формасы булу таләп ителә, шуңа да электрон кушымталар, дәреслекләр төзү юнәлешендә актив эш алып барыла.

## 1. ЭЛЕКТРОН КУШЫМТАЛАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ УКЫТУ ПРОЦЕССЫНДАГЫ РОЛЕ

Җәмгыятебез тормышының күп тармакларында чагылыш тапканча, компьютерлар акрын гына җитештерү процессыннан мәгълүматны эшкәртү һәм саклау чараларының күпчелек өлешен табигый рәвештә кысырыклап чыгарачаклар. Әлеге процессны дәлилләү өчен Eduventures.com фирмасының аналитигы Егин Чен сүзләрен китерергә була: «Биш елдан белем бирү тармагында электрон китап чыгару шактый зур көчкә әйләнәчәк» [websoft.ru, 1999-2014]. Әлеге фикер 2003 елда прогноз рәвешендә әйтелгән иде, бүгенге көн чынбарлыгыннан чыгып карасак, әлеге тармакның үсеш этабы тагын да тизрәк темплар белән бара.

Укыту процессын, аның закончалыкларын, укыту методларының дидактик нигезләрен тикшерүгә багышланган хезмәтләрендә И.Я. Лернер [Лернер И.Я.: 1981, 1980] яңа технологияләрне куллануга да тукталып уза. Мәгариф өлкәсендәге мәсьәләләрне чишүдә артта калмау, мәгълүмати технологияләрнең потенциалын киң куллану өчен тиешле техник һәм методик эшкәртмәләр кирәклеген ассызыклап үтә.

Электрон дәреслекләр концепциясе, аларны төзү, куллану мәсьәләләре С.В. Тевелева [Тевелева С.В.: 2000, 48-51], В.Н. Лаврентьев [Лаврентьев В.Н.: 2000, 87-91], А.Ю. Уваров [Уваров А.Ю.: 1999], Л.Х. Зайнутдинова [Зайнутдинова Л.Х.: 1999] һ.б. галимнәрнең тикшерү объекты булып тора.

Мультимедиалы кушымталарны ясау һәм аларны куллану мәсьәләләре С.А. Христочевский [Христочевский С.А.: 1999, 2000] хезмәтләрендә тикшерелә, өлешчә Е.С. Полат [Полат Е.С.: 2001] тарафыннан өйрәнелә.

С.А. Христочевский электрон дәреслекләрне ясау процессы барышында шактый кыенлыклар белән очрашырга туры килүен күрсәтә. Инде эшләнгән электрон дәреслекләрнең кимчелекле якларына да аерым туктала. Мәсәлән, аларның программистлар коллективы тарафыннан инде искергән укыту ысулларына нигезләнеп, тәмамланган продукт буларак эшләнүен билгеләп үтә. Әлеге продуктларның асылында мондый төр дәреслекләр белән эшләү методикасы булмавын да ассызыклый.

Электрон кушымталарга аңлатма язулары еш кына бөтенләй бирелми, ә бирелгән очракта аның белән эшләүнең методикасы чагылдырылмый. Нигездә, аңлатмаларда әлеге электрон кушымталарны куллану өчен нинди техник мөмкинлекләр таләп ителүе генә күрсәтелә, калганын кулланучы үзе төшенергә тиеш була. Шулай итеп, шактый вакыт продукт белән танышуга гына китә, әле эшне башлап җибәрү өчен функция, мөмкинлекләрне өйрәнергә кирәклеге игътибардан читтә кала. Әлеге проблема программистлар белән методистларның үзара килешеп эшләмәүләреннән барлыкка килә. Программистлар еш кына кулланучыны компьютер өлкәсен яхшы белүче буларак күзаллый һәм продуктны аңа ориентлаштыра. Ләкин мәктәп программасы өчен ясалган электрон кушымталар турында сүз барганда, яшь үзенчәлекләрен дә, кулланучыларның компьютерны төрле дәрәҗәдә белүчеләр булуын да истә тотарга кирәк. Электрон кушымталарның күбесендә биремнәр өйрәнгән материалны кабатлау, тестлар эшләү, тренировка рәвешендә эшләнгән. Белемнәрне ныгытуда бу, әлбәттә, бик әһәмиятле. Ләкин әгәр дә сүз укыту, белем бирү әсбабы турында бара икән, бу гына аз, башка укыту максатларын да онытырга ярамый.

Искә алынган хезмәтләрдә электрон укыту әсбапларын эшләүнең технологиясен булдыру актуаль мәсьәлә буларак билгеләп үтелә. Без дә гомуми технология эшләнгәннән соң һәр фәннең үзенчәлекләрен истә тотып, аерым фәннәргә караган критерийлар да эшләнергә тиеш дип саныйбыз.

Электрон кушымта ачык мәгълүмати системаны тәшкил итәргә, укытучы билгеле бер шартларда әлеге кушымтаның эчтәлеген төрле тәртиптә, аерым бер модификациядә куллана алырга тиеш. Шул ук вакытта укучылар өчен продуктны мөстәкыйль куллану мөмкинлеге саклану мөһим. Яңа мәгълүматны табу, аны анализлау күнекмәләре формалаштыру өчен электрон кушымта отышлы вариант. Яңа белем бирү, белемнәрне ныгыту, кабатлау этаплары, белешмә материаллар – барысы да электрон кушымтада урын алырга тиеш.

ЭВМ, комьютерлар, микроэлектроника, информатика үсеше белән мәгълүматны саклау, эшкәртү һәм тапшыру электрон ча-

ралары глобаль инфраструктурага, мәгълүмати ресурслар теләсә кайсы илнең милли байлыгына әйләнә. Аларны куллану илнең экономик көчен чагылдыра. Мәгълүматны тәкъдим итү, саклау, тапшыру һәрвакыт кешелек цивилизациясен формалаштыра. Кешелек мәгълүмати технологияләр үсеше өлкәсендә китап һәм почтадан радио, телеграф, телефон аша мультимедиа эш станциясенә чаклы юл үтә. Мультимедиа эш станциясе текст, графика, тавыш, видео һәм телевизион сурәт рәвешендәге мәгълүмат белән эшләү мөмкинлеген бирә. Һәр кеше, мәгълүмати җәмгыять субъекты буларак, бүгенге көндә төрле төрдәге мәгълүмат киңлекләрендә эшли белергә тиеш. Башкача әйткәндә, мәгълүмати җәмгыятьнең актуаль мәсьәләсе – принципиаль рәвештә яңа мәгълүмати мәдәният формалаштыру. Әлеге төшенчәгә дөньякүләм мәгълүмати киңлеккә керү, профессиональ мәгълүмати процессларда катнашу, төрле төрдәге мәгълүмати ресурслар белән эш итә белү, мәгълүматны тәкъдим итә торган мультимедиа чараларны куллана алу мөмкинлеге керә. Мәгълүмати мәдәният формалашу күбесенчә мәктәптә һәм югары уку йортында, информатиканың яңа юнәлешләрен өйрәнү нәтиҗәсендә бара. Әлеге юнәлешләргә телекоммуникацияләр, локаль һәм глобаль челтәрләр, бүленешле хисаплаулар һәм мәгълүмат базалары, мультимедиа һәм гипермедиа технологияләре керә.

Яңа технологияләрне кертү идеяләрнең һәм мәктәп, һәм югары уку йортларында белем бирү системасының һәрдаим яңартылып торуын, шулай ук әлеге технологияләрне җентекләп өйрәнә һәм укыту процессына кертә алучы яңа педагогик кадрлар әзерләүне таләп итә. Әлеге проблема егерменче гасырның сиксәненче елларында А.П. Ершов [Ершов А.П.: 1992, 1984, 1981, 1995], Б.С. Гершунский [Гершунский Б.С.: 1987], Е.И. Машбиц [Машбиц Е.И.: 1986, 1988], Н.Ф. Талызина [Талызина Н.Ф.: 1985, 34-38] һәм башка галимнәр тарафыннан күтәрелә. Г.А. Бордовский [Бордовский Г.А.: 1994, 1995, 1996, 1997, 1993], В.А. Извозчиков [Извозчиков В.А.: 1991, 1996], Б.Я. Советов [Советов Б.Я.: 1977, 1978, 1985] хезмәтләрендә мәгълүмати җәмгыять педагогикасына һәм өзлексез белем бирү системасында мәгълүмати технологияләргә шактый урын бирелә. Информатика өлкәсендә фундамен-

таль әзерлек мәсьәләләрен В.В. Лаптев, М.В. Швецкий [Швецкий М.В.: 2000, 1994] өйрәнә. Югары уку йорты мәгълүмати кырына һәм бу өлкәдә эшләүче педагогик кадрларны әзерләүгә В.П. Соломин [Воробьев В.И., Румянцев И.А., Соломин В.П.: 1995] [Соломин В.П.: 2011, 124-127] хезмәтләрендә игътибар бирелә. Н.В. Баранова [Баранова Н.В.: 2000, 43-47] тарафыннан мәгълүмати технологияләргә өйрәтүдә объектка юнәлтелгән проектлаштыру идеяләрен кертү тәкъдим ителә. И.В. Симонова [Симонова И.В.: 2000] тиз темплар белән үсә торган Интернет аша белем бирү шартларында укыту модельләрен эшләп чыгара. И.Л. Братчиков [Братчиков И.Л., Марусева И.В., Казаков А.Ю.: 1993] ясалма интеллект мәсьәләләрен тикшерә. Н.В. Макарова [Макарова Н.В.: 2004], Т.А. Бороненко [Бороненко Т.А.: 1995] хезмәтләрендә мәктәптә информатика укыту методикаларын эшләү мәсьәләләренә шактый киң урын бирелә.  И.Я. Ланинаның [Ланина И.Я.: 1985] танып белүне үстерүгә юнәлгән хезмәтләре билгеле. Укытуның методик системаларын камилләштерүгә  Г.Г. Хамов [Хамов Г.Г.: 1993] зур өлеш кертә.

Шулай да укыту процессында мультимедиа технологияләрен куллану мәсьәләләре ачык булып кала бирә. Аңлашыла ки, мультимедиа технологияләрен куллану педагогик югары уку йортларын тәмамлаучыларның махсус мәгълүмати әзерлекләре, мәгълүматны эзләү, анализлау һәм туплау күнекмәләре камил булуын, идея, төшенчә, процессларның сурәтләнешен визуаль рәвештә күзаллый һәм үзләренең идеяләрен төрле мәгълүмат төрләре аша чагылдыра белүләрен таләп итә. Алгоритмлаштыру һәм программалаштыру телен өйрәнгәндә, укучыларда логик фикерләү үсеш ала, шул ук вакытта А.В. Антонов [Антонов А.В.: 1988], Б.М. Величковский [Величковский Б.М.: 1985, 1982], А.А. Гостев [Гостев А.А.: 1992] кебек психологлар кеше мәсьәләне ике төрле юл белән чишә ала дип белдерә. Аларның берсе күрсәтмә-интуитив (наглядно-интуитивный), икенчесе сүз-логик (словесно-логический). Беренче очракта кеше аңында объектның гомумиләштерелгән образы туа. Шушы образ белән калганнары чагыштырыла. Икенче очракта репрезентация (күзаллау) сүз ярдәмендә формалаша, үз эчендә фикерләү рәвешен ала. Сулъяк ярымшары вер-

баль мәгълүмат, а уңъяк ярымшары, күпчелек рәвештә, образлы мәгълүмат белән эш йөртә. Танып белүнең ике дәрәҗәсе турындагы теория («двойное кодировоние») авторы А.Пайвио [Аллан Пайвио: 2011] тәкъдим иткән концепция дә шуңа нигезләнә. Алда искәртеп үтелгән хезмәтләр нигезендә, без ике ярымшарны да активлаштыру нәтиҗәсендә танып белү процессының потенциалын шактый үстерергә була дип фаразлый алабыз. Мәсьәлә шунда ки, укыту процессында компьютерлар куллану, нигездә, вербаль фикер йөртүне генә үстерә. Бу психологларда берникадәр борчу уята. Танып белү процессының гомуми психик процесслары турында истә тотарга кирәк дип искәртәләр алар. Д.А. Поспелов [Поспелов Д.А. 1996] фикеренчә, алгоритмик фикерләү өчен объектларны таркату, декомпозиция операцияләре хас. Образлы иҗади фикерләү бу вакытта катнашмый. Ләкин мәгълүмати технологияләрнең бүгенге үсеш дәрәҗәсендә компьютер технологияләрен кулланып, баш миенең ике ярымшарына да тәэсир итү, образлы фикерләүне арттыруның өстәмә мөмкинлекләре барлыкка килде.

Интеллект үсешенә бәйле рәвештә кабул итүне өйрәнгән Ж. Пиаже [Пиаже Жан: 1994] интеллектуаль операцияләр бөтен структура формасында башкарыла һәм объектив белемнәр һәрвакыт билгеле бер структур хәрәкәткә буйсына дигән фикер әйтә. Әлеге структуралар конструкция нәтиҗәсе була. Ж. Пиаже [Обухова Л.Ф.: 1981] психологиягә ябык һәм кайтарма система булган группировка төшенчәсен кертә. Ә интеллектуаль үсешне эзлекле, берсеннән- берсе чыга торган группировкалар рәвешендә тасвирларга тәкъдим итә. Нәкъ менә группировкалар фикер берәмлеге булып тора. Шулай итеп, психологларның «о двойном кодировании» һәм Ж.Пиаженың конструктивизм идеяләре педагогларның игътибарын мультимедиа технологияләренә юнәлтә. Мультимедиале технологияләр үз эчендә бер үк вакытта объектның образын, төрле мәгълүмати күзаллауларны: графика, тавыш, видео, процессны һәм хәрәкәтнең динамизмын реальләштерү, анимация рәвешендә объектларның үзгәрешен берләштерә.

Мультимедиале технологияләрне танып белү процессына кертү методикаларын эшләп чыгару актуаль мәсьәләгә әйләнде. Бу укытуның эффектлылыгын арттыруда шактый зур роль уйный

ала. Бу мәсьәләнең әһәмияте Б.Я. Советов [Советов Б.Я.: 1977, 1985] хезмәтләрендә дә ассызыклана, В.В. Александров [Александров В.В.: 1982, 2004] мәгълүматны график рәвештә җиткерү мәсьәләләре белән шөгыльләнә.

Р.М. Юсупов [Юсупов Р.М.: 2000] тарафыннан эшләнгән укыту процессын информатизацияләүнең фәнни-методик проблемаларын тикшерүгә багышланган хезмәттә әлеге проблеманың катлаулылыгы билгеләп үтелә. Соңгы проблема шактый катлаулы, чөнки сүз педагогик кадрлар турында гына түгел, ә шулай ук мәгълүмати технологияләрне эшләүчеләр хакында да бара, дип проблеманың тагын бер ягына игътибар итә галим. [Юсупов Р.М.: 2000, 94]. L. Plowman [Plowman L.: 1996] интерактив мультимедиале технологияләрне кертүнең авырлыкларын күрсәтә. Ул, укыту процессына мәгълүмати технологияләрне кертү өчен, укытучыларны программистлар тарафыннан барлык кулланучыларны истә тотып эшләнгән программалар белән тәэмин итү кирәклеген искәртә. Кагыйдә буларак, әлеге программаларда укыту процессын оештыруның психологик-педагогик, методик үзенчәлекләре искә алынмый, алар мәктәп стандартларына нигезләнми, укыту һәм эш планнары белән бәйләнмәгән. Бу исә укыту процессына кертү өчен укытучыларның үзләренә мультимедиале технологияләрне җайлаштыру ихтыяҗы тудыра. В.Г. Мануйлов [Мануйлов В.Г.: 2001, 70-77] мондый төр продукцияләрне җитештерү өчен, Microsoft Office 97 шаблоннар мастерын тәкъдим итә. Ләкин бүгенге көн күзлегеннән чыгып караганда, әлеге программа актуальлеген югалтты. Тиешле дәрәҗәдә интерактивлык булдыру өчен дә, аның функциональ мөмкинлекләре җитми.

С.А. Христочевский [Христочевский С.А.: 2000] да электрон дәреслекләрнең һәм энциклопедияләрнең үзенчәлекләрен теоретик яктан тикшергән хезмәтендә, аларны эшләү методикасын булдыру проблемасын куя. Аның хезмәтендә мультимедиале технологияләрне куллануның фән тарафыннан дәлилләнгән уңай якларына басым ясала. Укыту процессында мультимедиале технологияләрне куллану

- мәгълүматны кабул итү, игътибарны көчәйтү, хәтер һәм интеллектны үстерүдә югары күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирә;
- образлы кабул итү аша кешенең ми эшчәнлеген, уйлау сәләтен активлаштыра.

Әлеге хезмәттә мультимедиале технологияләрнең төшенчәләр системасы, практик методлары һәм мәгълүмати компонентларын эшкәртү чаралары күрсәтелә. Мультимедиале технологияләр өлкәсендә белемнәрне, күнекмәләрне формалаштыру һәм аларны укыту процессында куллану концепциясе тәкъдим ителә. Шулай ук текст, график, аудио, видео мәгълүматларны эшкәртүнең практик методлары билгеләнә. Аларны эшкәртүнең конкрет программалары һәм техник җиһазлары тәкъдим ителә. Сайлау критерийлары буларак универсальлек һәм интегральлек күрсәтелә. Объектка ориентлашкан программалаштыру технологиясенә нигезләнгән интеллектуаль интерфейс концепциясе эшләп чыгарыла һәм тормышка ашырыла. Әлеге концепция нигезендә А.И.Герцен исемендәге Россия Дәүләт педагогика университетында (РГПУ) автоматлаштырылган системалар кертелә. MS Excel электрон таблицалар мохитендә мультимедиале технологияләр өлкәсендәге белемнәрне, күнекмәләрне үзләштерү һәм аларны куллану дәрәҗәсен бәяләүнең автоматлаштырылган программасы эшләнелә.

Алда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, мультимедиале технологияләрне куллануның теоретик һәм методологик проблемаларын чишү психологик, техник, педагогик яктан да әһәмиятле. Бу өлкәгә караган тикшеренүләр теориядән тиз арада практикага да күчә, алар нигезендә программалар ясалып, апробация үтә.

Терминологиягә килгәндә, еш кына электрон кушымта дигән төшемчә белән беррәттән мультимедиа кушымта дигән вариант белән дә очрашабыз. Нәрсә соң ул мультимедиа? Аңа нинди билгеләмә бирелә?

Мультимедиа – тавыш, анимацияле компьютер графикасы, видеокадрлар, статистик сурәтләр һәм текстлар белән бер үк вакытта эшләү мөмкинлеге бирә торган интерактив (диалогик) системалар. Әлеге термин кулланучыга бер үк вакытта берничә

канал ярдәмендә тәэсир итүне күз алдында тота. Бу вакытта кулланучыга, гадәттә, актив роль тапшырыла. Башкача әйткәндә, мультимедиа – текст, графика, анимация, цифрга күчерелгән статик сурәтләр, видео, тавыш, сөйләм кебек мәгълүмат типларын компьютерга кертү, эшкәртү, саклау, тапшыру һәм чагылдыру (чыгару) мөмкинлеген бирә торган технологияләр суммасы.

Мультимедиа сүзе компьютер технологияләре белән бәйсез рәвештә барлыкка килә. Аны беренче тапкыр 1966 елда инглиз җырчысы Боб Голдштейн үзенең яңа шоу-программасын әзерләгәндә куллана. Соңрак бу термин белән төрле тавыш һәм видео эффектлары булган теләсә нинди күңел ачу продуктын атый башлыйлар. Бары тик 1990 елларда гына әлеге сүзгә билгеләмә бирелә: «мультимедиа (multimedia) – текст, тавыш, видеосурәт, график сурәт һәм анимацияне (мультипликацияне) компьютер системасында берләштерү мөмкинлеген бирә торган заманча компьютер мәгълүмати технологиясе». Билгеләмәнең оригиналы инглиз телендә: «Multimedia includes a combination of text, audio, still images, animation, video, or interactivity content forms».

Элек укытучы тарафыннан үткәрелгән дәрестә магнитафон тасмасы, кино, слайдлар һ.б. теләсә нинди техник укыту чаралары кулланылган очракта мультимедиале дәрес дип атыйлар иде. Бүген исә әлеге термин белән мультимедиале укыту программасы, компьютер яки ноутбук, проектор, веб-камера кулланылган дәресне билгелиләр. Укыту теориясендә хәтта берничә тикшерү юнәлеше дә барлыкка килде, аерым алганда, мультимедиале укыту теориясе.

Рәсми булмаган термин да барлыкка килде: эдьютейнмент – «edutainment» – «education» – «мәгариф» һәм «entertainment» – «күңел ачу» сүзләреннән барлыкка килгән яңа сүз. Эдьютейнмент укыту һәм күңел ачу арасындагы бәйләнешне чагылдыра, ягъни укучы күңел ачу максатын күз алдында тотып, игътибарын уку процессына туплый [Дьяконова О.О.: 2013, 58-61].

Нәкъ менә мультимедиа чаралары укучыларга көчле тәэсир итә. Алар укучының күпчелек сизү компонентларын уку мәгълүматын кабул итү процессына катнаштырып, уку процессын баета,

белем бирүне эффективрак итә. Алар безнең заманның объектив реальлегенә әйләнде [Соболева А.В.: 2013, 119-123].

Мультимедиа технологияләре белән мәктәпкә яңа фикерләү идеологиясе дә килде. Элек мәктәптә кабул ителгән укыту моделе буенча укыту технологиясенең үзәгендә – укытучы; укучылар арасында яшерен ярыш бара; укучылар дәрестә пассив роль уйный; укытуның асылы – белемнәрне (фактларны) тапшыру. Аңа алмашка килүче яңа укыту моделе түбәндәге кагыйдәләргә нигезләнә: укыту технологиясенең үзәгендә – укучы; уку эшчәнлегенең нигезендә – хезмәттәшлек; укучылар уку процессында актив роль уйный; технологиянең асылы – укучыларның үзлектән белем алу һәм коммуникатив компетенциясен үстерү [festival.1september.ru: 2013].

Дәреснең мультимедиа өлеше куллану дәрәҗәсе һәм вакыты буенча төрле булырга мөмкин. Мультимедиале дәреснең максатлары: яңа материалны өйрәнү; яңа мәгълүматны җиткерү һәм укучыларның күзаллавын киңәйтү; үткән материалны кабатлау; алган белемнәрне, күнекмәләрне практик куллану; белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.

Мультимедиале кушымтаны куллану өчен компьютер, ноутбук, проектор кебек техник чаралар таләп ителә. Ул турыдан-туры Интернет аша, онлайн режимында яки алдан дискка, флешкага яки кулланыла торган техник чараның хәтеренә күчерелеп, офлайн режимында күрсәтелергә мөмкин.

Инде билгеләп үтелгәнчә, мультимедиане куллану дәрәҗәсе һәм вакыты дәреснең максаты һәм эчтәлеге белән билгеләнә. Ләкин, практик яктан чыгып, мультимедиале кушымталарны куллануның гомуми, эффектив очракларын аерып чыгаралар:

1. Яңа материалны өйрәнгәндә. Бу күрсәтмә чаралар ярдәмендә иллюстрацияләү мөмкинлеген бирә. Теге яки бу процессның үсеш динамикасын күрсәтергә кирәк булганда аеруча файдалы.

2. Яңа теманы ныгытканда. Бу очракта укытучы визуаль яки аудио контентка мөрәҗәгать итә ала.

3. Белемнәрне тикшергәндә. Компьютер ярдәмендә тест уздыру – үз-үзеңне тикшерү һәм үз-үзеңне реализацияләү, бе-

лем алу өчен яхшы стимул, үзеңне күрсәтү мөмкинлеге. Укытучы өчен укучылар алган белемнәрне сыйфатлы рәвештә контрольдә тоту, билгеләрне туплауның программалаштырылган мөмкинлеге.

4. Белемнәрне тирәнәйтү өчен, дәрескә өстәмә материал буларак. Укучыларның күзаллавын киңәйтү максатыннан, фән белән кызыксындыру, мотивлаштыру чарасы буларак кулланыла ала.

5. Фронталь мөстәкыйль эшләрне тикшергәндә. Телдән тикшерү белән берлектә, нәтиҗәләрне визуаль рәвештә контрольдә тоту мөмкинлеген бирә.

6. Белем бирү бурычларын тормышка ашырганда. Мөстәкыйль эшне эшләргә, билгеле бер этаптагы һәм соңгы нәтиҗәләрне контрольдә тотарга ярдәм итә. Бу очракта, беренче чиратта, укытучы өчен техник ярдәмлек ролен уйный.

Укытучы коллегалары тарафыннан эшләнгән, профессиональ сайт һәм форумнарга урнаштырылган әзер электрон кушымталар базасын куллана ала. Бу аңа дәрескә әзерлек процессын җиңеләйтәчәк. Шулай ук әлеге электрон кушымталарны үзенең дәресләренә туры килә торган итеп, аны үз укыту программасына яраклаштырырга мөмкин. Бу очракта укытучыдан, тәкъдим ителгән электрон кушымталар белән алдан танышып, аларны куллануның үзенең дәресләренә туры килә торган системасын булдыру, иҗади якын килү сорала.

Мультимедиа белемнәрне үзләштерү һәм тәкъдим итү процессына иҗади якын килү мөмкинлеген бирә. Гомумән, соңгы вакытта укытучылар Интернет ресурсларын актив куллана башлады, бу укучыларда өйрәнелә торган фәнгә кызыксыну уятырга ярдәм итә, мөмкинлекләрне киңәйтә. Кызыксыну уяту яки өйрәнүне мотивлаштыру укыту процессында иң авыр элементларның берсе.

Мультимедиале Интернет-ресурс – төп мәгълүмат мультимедиа рәвешендә бирелгән Интернет-ресурс. Бу заманча һәм бик уңайлы механизм. Ул классик функцияләрне алыштырмый, ә кулланучылар өчен мөмкинлекләрне киңәйтә. Бүген мондый төр электрон ресурслар күп, куелган максаттан чыгып, аларның төр-

лесен сайлап алырга була. Мультимедиале Интернет-ресурсларга түбәндәгеләр хас:

- төрле типтагы мәгълүмат бирелә (текст белән генә чикләнми, тавыш, графика, анимация, видео һ.б.);
- материалларның күрсәтмәлеге;
- үзлектән эшләү мөмкинлеге;
- моменталь рәвештә җавап алу мөмкинлеге һ.б.

Бүген гади сайтларга да мультимедиа мөмкинлекләрен өстиләр. Чөнки кулланучылар игътибарын яулау өчен интерактивлык сорала. Мондый төр сайтларның күпчелеге күңел ачу форматында булса да, Интернет челтәрендә уку-укыту, тел өйрәнү сайтлары аерым бер сигмент булып тора. Кыскасы, мультимедиа технологияләр – уку процессын информатизацияләүнең иң перспектив юнәлешләренең берсе. Заманча мәгълүмати технологияләрне уңышлы куллануның перспективалары программа һәм методик җиһазлауны, материаль базаны камилләштерү, укытучыларның квалификациясен күтәрү белән билгеләнә [Соболева А.В.: 2013, 119-123].

Электрон кушымта төшенчәсе мультимедиагә караганда киңрәк. Гадәттә, мультимедиа технологияләре электрон кушымтада кулланылган була. Электрон кушымталарның төрләре күп. Уку-укыту процессында кулланыла торганнарын аерым бер төркемгә чыгарырга була. Ләкин аларга карата аерым критерийлар, таләпләр эшләнелмәгән. Бүгенге көндә Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан электрон кушымталарның бер төре булган электрон формадагы дәреслекләргә карата гына төгәл таләпләр эшләнде. Ләкин әлеге продукт укыту процессына әле кертелә генә, димәк, апробация барышында таләпләрне камилләштереп, алга таба аларга үзгәрешләр кертелүе мөмкин.

Россиядә Федераль исемлеккә кергән дәреслекләрнең һәрберсенең электрон кушымтасы булуы мәҗбүрилеге безнең тарафтан инде билгеләп үтелгән иде. Әлбәттә, укытучы үзе укыткан дәреслекнең электрон кушымтасын әзер рәвештә куллана ала, ләкин башка дәреслекләр нигезендә ясалган электрон кушымталарның синтезын куллану да уңай нәтиҗәләр бирергә мөмкин. Бу

очракта укучыларның күзаллавын киңәйтү, төрле дәреслек һәм укыту программаларының иң уңышлы элементларын дәрескә табигый рәвештә кертеп җибәрү мөмкинлеге туа.

Алда әйтелгәннәргә берникадәр нәтиҗә ясап, мультимедиале укыту технологияләре, электрон кушымталарны куллану традицион укыту методлары белән чагыштырганда, өстенлекләргә ия булуын билгели алабыз. Әлеге технологияләр сөйләм күнекмәләре булдыру һәм аларны төрле комбинацияләрдә куллану; коммуникатив ситуацияләр булдыру; индивидуаль якын килеп эш итү һәм укучының мөстәкыйль эшчәнлеген интенсификацияләү мөмкинлекләрен бирә.

## 2. ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЭЛЕКТРОН КУШЫМТАЛАРНЫ КУЛЛАНУ

Бүгенге көндә электрон дәреслекләр турында дискуссия дәвам итә. Дәреслекнең электрон формасы электрон дәреслек буламы? Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының укыту программаларын тормышка ашыруда куллануга тәкъдим ителгән дәреслекләрнең федераль исемлеген формалаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турындагы канунында дәреслекнең электрон формасына мондый билгеләмә бирелгән. Электрон форма – структура, эчтәлек һәм бизәлеше буенча дәреслекнең басма формасы белән тәңгәл килүче, дәреслек эчтәлеген киңәйтүче һәм баетучы мультимедиа элементлары һәм интерактив сылтамалары булган электрон басма. Аңа карата түбәндәге таләпләр билгеләнгән:

- электрон формадагы һәм басма дәреслекләрнең структурасы, эчтәлеге һәм бизәлеше үзара тәңгәл килергә;
- дәреслекнең электрон формасында басма формадагы иллюстрацияләр тулы күләмдә чагылыш табарга (электрон формада аларның адаптациясе һәм (яки) композициясе үзгәреше искә алына);
- дәреслекнең электрон формасында материалны үзләштерү өчен кирәк булган, педагогик яктан дәлилләнгән мультимедия һәм (яки) интерактив элементлар (сурәтләр галереясы, аудиофрагментлар, видеороликлар, презентацияләр, анимацион роликлар, интерактив карталар, тренажерлар, лаборатор эшләр, экпериментлар, һәм (яки) башкалар) саны; контроль һәм үзконтроль чаралары булырга;
- электрон дәреслектә тиешле һәм җитәрлек дәрәҗәдә мультимедиа элементлары булырга;
- электрон дәреслектә тиешле һәм җитәрлек дәрәҗәдә интерактив элементлар булырга;
- электрон дәреслек өч яки өчтән артык операцион системада эшләргә, аларның икедән ким булмаганы мобиль җайланмалар өчен булырга;
- электрон дәреслек икедән ким булмаган электрон җайланмада (стационар яки персональ компьютер, шул исәптән интерактив такта, планшетлы компьютер һәм башкалар) эшләргә;

– кулланучыларның җайланмаларында Интернет һәм Интранет челтәрләренә тоташырудан башка (тышкы сылтамалардан тыш) эшләргә;
– кулланучы тарафыннан ясала торган закладка, кыска комментарийлар калдыру һәм аларга күчү мөмкинлекләре булырга;
– электрон дәреслек кулланучы өчен лицензион чикләүләре булмаган, һәркемгә ачык форматта булырга;
– электрон форматтагы дәреслекнең агымдагы бите эчтәлегенең басма дәреслектә кайсы биттә икәнлеген билгеләү мөмкинлеге булырга;
– электрон дәреслеккә кертелгән командалар уңайлы куллану мөмкинлеген тәэмин итүче вакыт интервалында эшләргә тиеш.

Ләкин дәреслекнең электрон формасы басма дәреслектән башка кулланыла һәм аны тулысынча алыштыра алмый, уку комплектының бер өлеше генә булып тора. Россия Федерациясендә мәгариф системасын информатизацияләүнең киләсе этабы тулысынча электрон дәреслекләргә күчү булырмы? Әлеге контекстта, без электрон дәреслек терминын кулланганда басма аналогы булмаган, уку материалын киңәйтүче, мәктәп программасы белән генә чикләнеп калмыйча, өстәмә белемнәр алырга мөмкинлек бирүче электрон әсбап турында сүз алып барабыз. Әлеге сорау ачык кала, фикер алышу дәвам итә. Бу сорауны теге яки бу якка хәл итүдә хәлиткеч факторларның берсе дәреслекнең электрон формаларына ихтыяҗ булыр, мөгаен. 2015 елдан мәктәпләр укыту процессында дәреслекнең нинди формасын куллануны үзләре хәл итәчәк. Әгәр электрон формага ихтыяҗ була икән, димәк, бу басма версиядән баш тартып, электрон дәреслеккә күчүдә катализатор булачак.

Мәгълүмати технологияләр укыту процессына бер көндә генә үтеп керми, әлбәттә, ләкин әлеге процессның зур тизлеге белән баруын билгеләп үтәргә кирәк. Билгеле ки, белемнәрнең төрле өлкәләренә (табигать, төгәл, гуманитар фәннәр) караган мультимедиа казанышларын куллануның бары тик бу өлкәне яхшы белүче профессионал гына бәяли алган үзенәлекләре бар [Алхазашвили Д.Н.: 2001]. Мәктәптә туган тел һәм әдәбиятны укытуда мәгълүмәти һәм компьютер технологияләрен куллану

тенденцияләрен билгеләп карыйк. Әлеге процесс дәресләрдә төрле презентацияләр куллану, слайдлар күрсәтүдән башланып китә. Укытучы алдан ук дәрескә материалны әзерли, әлбәттә, монда сүз офлайн режим турында бара. Мәктәпкә компьютер белән тәэмин итү башлангач, мөмкинлекләр тагын да киңәйде. Укытучыга зур ярдәм күрсәткән мультимедиалы кушымталар пәйда булды. Башта аларга шикләнеп караучылар, тел һәм әдәбият дәресләрендә компьютер технологияләрен куллануга каршы чыгучылар еш очраса да, әкренләп аларны куллануның эффектив булуы, укучыларда материалга карата кызыксынуны арттыруы мультимедиалы кушымталарга укыту процессында ныклап кереп урнашырга мөмкинлек бирде. Мәктәпләрнең Интернет челтәренә тоташтырылуы төрле электрон ресурсларны, шул исәптән электрон китапханәләрне куллануга юл ачты. Шушы ук вакытта мәктәпләрдә белем бирү системасын информатизацияләү процессы да актив башкарылды: электрон журналлар, көндәлекләр кертелде.

Мәгариф оешмаларын информатизацияләү – мәгариф үсешендәге өстенлекле юнәлешләрнең берсе. Мәктәпләр интерактив такталар, мультимедиа проекторлары белән җиһазлана, дәресләрдә компьютер технологияләре кулланыла. Компьютер технологияләрен нәтиҗәле файдалану – хәзерге көндә укыту методикасының мөһим бурычы.

Дәрес – уку-укыту эшчәнлегенең иң төп урыны. Нәкъ менә дәрестә укучылар укытучылары җитәкчелегендә үз интеллектларын һәръяклап үстерү, белем алу һәм тормыш мәсьәләләрен хәл итү өчен мәгълүмат туплау максатында компьютер технологияләрен кулланырга өйрәнә. Компьютер – белем алу өлкәсендәге максатларга ирешү, укыту процессын баету, бала шәхесе һәм укытучының һөнәри осталыгы үсешенә йогынты ясау чарасы ул. Укытучыдан әлбәттә һөнәри осталык таләп ителә:

- компьютердан файдалануның үзенә хас үзенчәлекләрен педагогик әсбап буларак аңлау, аның мөмкинлекләрен һәм җитешсез якларын билгели белү;
- уку материалын аңлата алу һәм укучылар белемен тикшерүнең бер ысулы буларак электрон ресурслардан файдалана белү тәҗрибәсенә ия булу;

- укытучылар өчен тәкъдим ителгән кулланма программа һәм ярдәмлекләр белән эш итә белү алымнарын үзләштерү кирәк.

Дәрестә компьютердан файдалану максатчан һәм методик яктан нигезләнгән булырга тиеш. Укытуның башка нәтиҗәлерәк чараларын эшкә җигү мөмкин булганда, компьютер куллану мәҗбүри түгел. Башка укыту ысуллары белән чагыштырганда югарырак нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеге биргән очракта гына мәгълүмати технологияләргә мөрәҗәгать итү мөһим. Әлеге технологияләр яңа материалны өйрәнү дәресләрендә, осталык һәм күнекмәләрне үзләштергәндә, шулай ук практик дәресләрдә яхшы нәтиҗәләр бирә.

Укытучылар татар теле дәресләрендә компьютер технологияләрен куллануның эффектив булуын һәм укучыларда тел өйрәнүгә карата кызыксынулары артуын билгеләп үтә. Алар профессиональ форумнарда, шәхси сайтларында, матбугат битләрендә дөнья күргән мәкаләләрендә, фәнни конференцияләрдә ясаган чыгышларында татар теле дәресләрендә компьютер технологияләрен куллану тәҗрибәләре белән уртаклашалар.

Хәзер мәктәптә кабинетлар компьютер, мультипроектор белән җиһазландырылган һәр дәрестә компьютер технологиясен куллану мөмкинлеге бар. Бу исә үз чиратында дәрестә укучыларның эшчәнлеген активлаштыруга да, дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрүгә дә ярдәм итә. Инновацион белем бирү, иң беренче чиратта, мәгълүмати – комьютер технологияләренең үсеше белән бәйле. Дәрестә компьютер технологияләрен куллану күрсәтмәлелекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә.

ТР Чистай шәһәре16 нчы гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары Дәүләтшина Д.Р., Афзалова Р.А., Ситдикова М.З. компьютер технологиясен дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда куллану торган саен камилләшә баруын ассызыклыйлар. Аеруча да рус аудиториясендә дәресләрдә темага кагылышлы презентацияләрне куллану отышлы, дип саныйлар һәм эш тәҗрибәләре белән уртаклашалар: “Рус телле балаларны аралашуга өйрәтү диалоглар аша ирешелә, аларны кызыксынды-

ру максатыннан диалог темасына туры килгән слайдлар файдаланыла. Рәсемгә карап яңа сүзләр, гыйбарәләр туа һәм сөйләмгә кереп китә.

Әйтик, дәрестә әңгәмә корган вакытта укучыларның сүзлек байлыгы җитмәү һәрвакыт сизелә. Шуңа да укытучы алдында яңа сүзләрне тиешле һәм урынлы куллана белергә өйрәтү бурычы тора. Яңа сүзләрне язып куеп кына истә калдыру кыенрак, шуңа да еш кына күрсәтмәлелеккә мөрәҗәгать итәбез. Я презентация, я кыска гына фильм күрсәтелә. Әлбәттә, укучыда аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәсен белү теләге уяна.

Дәрестә кулланыла торган иң отышлы заманча технологияләрнең берсе электрон дәреслекләр һәм ярдәмлекләр. Аларны компьютер һәм видеопроектор ярдәмендә эшләп, укучыларга зур күләмдә мәгълүмат бирергә мөмкин, бүгенгесе көндә CD-дискларга яздырылган электрон белешмәләр, “Татар телле заман”, “Мин татарча сөйләшәм” һ.б. компакт-дисклардан файдалану мөмкин. Шулар арасыннан “Сәләт” фонды чыгарган TATAR TELLE ZAMAN электрон дәреслекне аерып әйтергә була. Анда 50 темага 2000 сүз, 2500 рәсем, фотографияләр, 3 төрле дәрәҗәдәге күнегүләр, диалоглар, уеннар тупланган. Татар телен рус телле балаларга укытуда, укучыларның эшчәнлеген активлаштыруда бу чыганаклар укытучылар өчен зур хәзинә. Шулай ук без дәресләрдә Хайдарова Р.З. Галиева Н.Г җитәкчелегендә чыккан “Күңелле татар теле” электрон дәреслекләрен, кушымталарны бик уңышлы кулланабыз.. Әлеге дәреслекләр һәм ярдәмлекләрдәге материаллар укучыда тел өйрәнүгә кызыксыну тудыра. Аларның зәвыклы бизәлеше, биремнәр һәм текстларның сәнгатьчә бизәлеше, бизәлештә төсләрне урынлы куллану, тәкъдим ителгән текстларның һәм өзекләрнең балалар өчен кызыклы булуы, яшь үзенчәлекләренә туры килүе, биремнәр һәм сорауларның укучы башкарып чыга алырлык катлаулылыкта булуы, аудирование өлешләре булу бик тә яхшы.

- интерактив такта ярдәмендә дәрестә булган материалны күрсәтү генә түгел, ә яңаны да ясарга була. Бу бигрәк тә укучыларга ошый, чөнки әлеге тактада рәсем ясарга да, текстларга комментарий язарга да, диаграммалар һәм төрле графиклар сызарга

да була. Интерактив такта укучыларның мөстәкыйль эзләнүләрен, эшчәнлекләрен активлаштыруда зур урын алып тора.

- тест уздыру программалары исә укучыларны on-lin режимда эшләргә өйрәтә. Әлеге процесс барышында укучы бирелгән вакытны исәпләп тотарга, булган белемнәрен дөрес файдаланырга, уйларга һәм эзләнергә өйрәнә. Бу программа БРТ, БДИна әзерләнүдә зур ярдәм булып тора.

- интернет-ресурслардан дөрес файдалану бик күп дидактик мәсьәләләрне чишәргә ярдәм итә: рус телле балалар татар телендә текстлар тыңлый, татарча уку һәм сөйләм күнекмәләрен үстерә, ишетеп аңлау (аудирование) биремнәре эшли. Билгеле булганча, Интернет челтәрендә мәгълүмат эзләү – фәнни-эзләнү методының бер формасы, шуңа да ул дәреслек кысаларыннан чыгып, яңа белем эзләүдә безгә бик ярдәм итә.

Күптән түгел генә Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты белән берлектә татар тел укытучыларына ярдәмгә бала.рф сайты булдырылды. Мәгариф сыйфатын үстерү максатын алга куеп эшләнгән «БАЛА» дип аталучы мультимедиале интерактив китапханә татар телен һәм татар әдәбиятын өйрәнүгә юнәлтелгән. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен әлеге китапханә татар телен үзләштерү, татар әкиятләрен өйрәнү өчен ярдәмлек, татар телендә эшләнгән мультфильмнар иленә юл күрсәтүче. Без башлангыч сыйныфта укытканга күрә, дәрестә мультфильмнардан бик еш файдаланабыз. Мәсәлән, дәрес башында балаларга теге яки бу тема турында мәгълүмат бирелә. Аннан соң әсәр белән таныштырыла, балалар әсәрне башта дәреслектән укыйлар, бу әсәрне ничек күзаллаулары турында сөйлиләр. Шуннан соң мультфильм тәкъдим ителә. Балалар үзләренең фикерләре белән уртаклашалар, сорауларга җавап бирәләр. Шулай ук мультфильмның лексикасына да игътибар итәләр. Шуннан соң балаларга бу әсәрне сәхнәләштереп карау мөмкинлеге бирергә була. Бердән, рус телле балалар мультфильм геройларының татарча сөйләшкәннәрен ишетеп, телне аңларга һәм өйрәнергә омтылыш ала; икенчедән, әлеге мульфильмнарның һәркайсы тәрбияви әһәмияткә дә ия.”

Соңгы елларда тормышның барлык өлкәләренә дә компьютер үтеп керде. Шул ук вакытта уку-укыту системасына да. Заман мәктәбенең тормышын да информацион технологияләрдән башка күз алдына китереп булмый. Укучыларда уку процессына кызыксыну уяту өчен стандарт методлар белән генә чикләнергә ярамый. Укыту процессын информатизацияләү мәгариф өлкәсендә гаять зур мөмкинлекләр тудыра, чөнки аны белем бирүдә бик нәтиҗәле итеп кулланып була. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә дә компьютер технологияләрен максатка туры китереп кулланырга мөмкин. Укытуның бу төр яңа технологияләрен урынлы куллану укучыларның шәхси үзенчәлекләрен искә алырга, укытучы белән укучыларның бердәм эш алымнарын камилләштерергә, белем бирүнең сыйфатын күтәрергә мөмкинлек тудыра. Компьютер сыйныф тактасын да, тарату материалын да, дәреслекләрне дә алыштыра ала. Бүгенге балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Мәктәп баласы булган өйдә компьютер булмыйча калмый. Алай гына да түгел, хәзер кайбер балалар бакчасында да заманча технологияләрне үзләштерү мөмкинлеге тудырылган. Шуңа да еш кына укучы бүген укытучыга караганда да күбрәк белә. Әгәр дә элек мәктәп баласы өчен мәгълүмат чыганагы булып китап һәм мөгаллим торса, бүген ул барлык кызыксындырган сорауларга җавапны Интернет челтәре аша да таба ала. Шуңа да хәзерге педагоглар үсмерләрне үз фәне белән кызыксындыру, аларның игътибарын җәлеп итү өчен төрле хәйләләр уйлап табарга – шул ук мәгълүмати технологияләрне үзләштерергә һәм аларны укыту процессында кулланырга тиеш.

Компьютер технологиясеннән нәтиҗәле файдалану – хәзерге көндә укыту методикасының мөһим бурычы. Яңа төр эшчәнлек, компьютерда эшләү бәрабәренә укытуның сыйфатын күтәрүгә ирешү – компьютер технологиясенең иң өстенлекле ягы. Дәресләрдә компьютер куллану укучыларның актив һәм аңлап эшләвен тәэмин итүнең яңа алымы буларак дәресне тагын да күрсәтмәле итә.

Һәр укучының белем үзләштерүгә сәләте төрлечә була. Кайбер укучыларның ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек укучыларда күреп истә калдыруы өстенлек алган була.

Менә шушы вакытта нәкъ компьютер ярдәмгә килә. Чөнки мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә. Презентацион программаларны төзегәндә, укытучы аның эченә бик күп материал: төрле схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләр кертә.

Мондый программа белән танышканда, укучы үзен кино караучы итеп хис итә. Чөнки ул аның алдында бер-бер артлы кадрлар булып чыга.

Презентацион материалларны класстан тыш чаралар үткәргәндә, ата-аналар жыелышларында, әдәбият дәресләрендә язучының тормыш юлын, иҗатын өйрәнгәндә дә кулланырга мөмкин. Дәрес өчен презентацияләрне укучылардан ясату да белем сыйфатын күтәрүдә уңай нәтиҗә бирә. Ләкин шунысын да билгеләп үтү мөһим: башка предметлар буенча электрон пособияләр, төрле программалар сатуда бик күп, ә татар теле һәм әдәбияты өчен мондый әсбаплар әлегә юк дәрәҗәсендә. Шуңа да укытучыларга эзләнергә, презентацияләр төзү өчен төрле чыганаклардан материаллар тупларга туры килә [Шәмсетдинова Г.Я.: 2014].

Компьютер – укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы. Компьютердан файдалану укыту эшчәнлеген баета, укыту процессын кызыклы, нәтиҗәле һәм иҗади итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Дәрестә компьютердан файдалану максатчан һәм методик яктан нигезләнгән булырга тиеш.

Татар теле дәресләрендә дә мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек, әлеге технология – шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив булуы белән аерылып тора. Дәресләрдә компьютер куллануның юллары һәм ысуллары күптөрле [Имаева Г.М.: 2015].

Мәгълүмати компьютер технологияләрен укыту процессында куллану татар теленә кызыксынуны арттыра, дәрестә кирәкле эмоциональ атмосфера тудыруга, укучыны актив иҗади эшчәнлеккә тартуга, интеллектуаль шәхес формалаштыруга, реаль тормышта барлыкка килүче проблемаларны мөстәкыйль рәвештә чишә белү күнекмәсе булдыруга хезмәт итә.

Компьютер ярдәмендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә тренировка өчен күнегүләр күләме арта, катлаулылык ягыннан

дифференсация барлыкка килә. Моннан тыш мәгълүмати компьютер технологияләрен куллану дәресләрдә уңай эмоциональ фон һәм һәр укучы өчен уңыш ситуациясе барлыкка китерә. Шулай итеп, компьютер укучыларда үз эшчәнлегенә рефлексия формалаштыруга ярдәм итә, чөнки укучыга аның эшчәнлек нәтиҗәсен ачык күрсәтә [Нуруллина Л.Х.: 2015].

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә информацион технологияләрне куллануның өстенлекле яклары күп:

- материал югары күрсәтмәле дәрәҗәдә булуы белән отышлы;
- укучының шәхси сыйфатын ачыкларга мөмкинлек бар;
- контроль һәм үзконтроль дәрәҗәсе югары (материалны кабат укып, хатаны шунда ук төзәтергә, проблема чишүнең берничә вариантын файдаланып карарга мөмкин);
- укытуны интенсивлаштыру өчен тестларны нәтиҗәле кулланырга мөмкин. Укучыларның теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, белемнәрен бәяләү, ялгышларын ачыклау, аларны анализлау һәм төзәтү юлларын билгеләү өчен дә тестлар уңайлы;
- белем һәм күнекмәләрне ныгыту күнегүләрен күпләп эшләргә була;
- төрле дәресләрнең үзара бәйләнешен булдыру, дәрес укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү, дәрес эчтәлеген баерак һәм кызыграк итә.

Компьютер технологияләрен, электрон ресурсларны болар – укытучы өчен алыштыргысыз ярдәм. Бу инде, һичшиксез, татар теле һәм әдәбиятының эчтәлеген безнең әйләнә-тирәбездәге чынбарлыкка бәйләргә, шул мохиттә шәхеснең үзенең урынын билгеләргә ярдәм итә.

Төп максат буларак укытучылар укучыларда фәнни фикерләү, иҗади эшләү сәләтен үстерү, тәрбия эшендә югары нәтиҗәләргә ирешү, җәмгыятьтә үз урыннарын таба алырлык толерант шәхес тәрбияләүне билгели. Әлбәттә, бу максат гомумтәрбия максаты белән тәңгәл килә дип әйтергә дә була.

Компьютер дәресләрен әзерләгәндә укытучы түбәндәге бурычларны билгели:

- укучыларның белемгә булган омтылышларын үстерү;

- укучыларда махсус белем һәм күнекмәләр формалаштыру;
- укучыларда иҗади эшчәнлекне үстерү мөмкинлеген тудыру;
- укучыларның фикерләү сәләтен үстерү.

Дәресләрнең нәтиҗәлелеген арттыруда компьютер яки мәгълүмати технологияләр аерым урын алып тора.

Хәзерге вакытта дәресләрдә мультимедиа чаралары еш кулланыла. Мультимедиа технологияләрен куллану яңалыклар белән кызыксыну теләге уята. Беренчедән, укучыларның белемнәре формалаштырыла, икенчедән, сөйләм һәм мультимедиа чаралары белән эшләү күнекмәләре барлыкка килә. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә уен формасындагы күнегүләр телнең лексикасын, грамматикасын һәм структурасын җиңелрәк үзләштерергә ярдәм итә. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларына электрон уку-укыту ресурсларын, электрон кушымталарны файдалану, телне үстерү һәм саклау, дәрес укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү, дәрес эчтәлеклеген баерак һәм кызыклырак итү өчен зур ярдәмлек булып тора.

Дәресләр өчен презентацияләр ясау укучыларда зур кызыксыну уята. Аларны яңа теманы аңлатканда, материалны ныгытканда, язучыларның тормыш юллары белән таныштырганда, класстан тыш чараларда кулланып була.

Мультимедия технологиясе слайд-иллюстрацияләр күрсәтергә, читтән торып экскурсия үткәрергә мөмкинлек бирә. Әдәбият дәресләрендә мультимедия технологиясе куллану чагыштырмача анализ ясарга да ярдәм итә. Укучыларның татар телендәге мәгълүмат белән кызыксынулары татар әдәбияты дәресләрендә компьютер куллануның бик күп мөмкинлекләрен ача.

1. Интернет – татар әдипләренең яңа әсәрләрен һәм танылган язучыларның сирәк басмалары белән таныша алу мөмкинлеге бирә.
2. Компьютер ярдәмендә укыту – тиз һәм нәтиҗәле итеп үткән материалны актуальләштерә ала.
3. Укучыларның белем һәм күнекмәләрен бәяләүдә ярдәм итә.
4. Әдәбият дәресләрендә иллюстрацияләр, сәнгатьле уку күнекмәләре бирү һәм шагыйрьләрнең көйгә салынган җырла-

рын тыңларга мөмкин. Дәреснең төрле этапларында материал мультимедия аша бирелә.

Компьютер куллану дәресне кызыклырак, җанлырак итә. Информацион технологияләрне куллану, баланың иҗади мөмкинлеген, укуга кызыксынуын һәм мөстәкыйльлеген үстерә, күзаллауларын киңәйтә, фикерләү сәләтен камилләштерә.

Практика күрсәткәнчә, дәресләрдә компьютер куллану белем бирүдә традицион методлардан өстен булуын раслый, укучы дәресләрдә актив катнашучы була. Компьютер программалары укытуны индивидуальләштерүгә ярдәм итә, укучыларның мөстәкыйль эшләүләрен оештырырга мөмкинлек бирә.

Компьтер куллану түбәндәге очракларда үзен акларга мөмкин:

- объект һәм күренешләрне күрсәтү өчен;
- анимация, моделләштерү өчен;
- белемнәрне тикшергәндә тест сорауларына җавап алу өчен;
- виртуаль экскурсияләр үткәрү өчен.

Информацион технологияләрне куллану формалары:

1. Әзер электрон продуктларны куллану. Белем бирүнең сыйфатын яхшырта, күрсәтмәлелек принцибын ачык итеп тормышка ашырырга ярдәм итә.

2. Мультимедиалы презентацияләр куллану. Уку материалын тиешле бер эзлеклелектә биреп, материалны ассоциатив рәвештә истә калдырырга булыша.

3. Интернет челтәре ресурслары куллану. Белем алуга кирәкле информацияне таба белергә һәм системага салырга ярдәм итә.Бу җәһәттән http://belem.ru сайты укытучылар эшендә зур ярдәм. Биредә педагогларга, студентларга, мәктәп укучыларына, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга һәм, гомумән, татар теленә битараф булмаган һәркем өчен бай мәгълүмат урнаштырыла.

Татар теле укытучыларына укыту-тәрбия процессында куллану өчен белем чыганакларын тәкъдим итәбез:

http://belem.ru/ сайты – татар телендә белем бирүче укытучылар өчен зур ярдәм.

http://www.rusedu.ru/, http://metodisty.ru, http://nsportal.ru/ төрле презентацияләрне шул сайтлардан алырга була.

http://www.openclass.ru/node/224468 сайтында кроссвордлар.

http://ggulnaz.jimdo.com/, http://ras2203.narod.ru/ – Татарча мультфильмнар, спектакльләр.

http://qushlawich.ru/node/134 – Кушлавыч авылы сайты.

http://ras2203.narod.ru/shubino-karaoke.htm – сыйныфтан тыш чаралар үткәргәндә куллану өчен татарча караоке урнаштырылган.

Мультимедиа чаралары белән эшләү дәрес формаларын төрләндерү мөмкинчелеге бирә һәм аны дәреснең төрле этапларында кулланырга була:

- проблемалы ситуация тудыру өчен;
- яңа материалны аңлату өчен;
- өй эшен тикшерү өчен;
- дәрес барышында белемнәрен тикшерү өчен.

Видео-аудио һәм текст материалын берләштерү теманы комплекслы ачарга, аны иҗади кабул итәргә, укучыларның активлыгын күтәрергә булыша.

Дәресләрдә мәгълүмати-компьютер технологияләрнең төрле формаларын куллану, югарыда ассызыклап кителгәнчә, укучыларның белемнәрен тирәнәйтә, күззаллауларын үстерә. Предмет буенча өлгерешләрен арттыра. Мөстәкыйль эшләргә өйрәтә. Үз уңышларын күреп, сөенү, куану хисләрен тудыра.

Әгәр укытучы үзе үзләштергән методлар, алымнар белән генә эшләсә, аның хезмәте бик чикләнгән булыр иде. Андый укытучы белем бирүдә югары нәтиҗәләргә ирешүдән генә туктап калмый, ә шәхес буларак та үсүдән туктый. Инновацион алымнар куллану гына укытучының ителлектуаль үсүенә ярдәм итә. Ул аны яңа белемнәр, яңа мәгълүматлар эзләүгә этәрә һәм аларны укыту-тәрбия эшчәнлегендә тормышка ашырырга булыша. Шулай итеп инновацион эшләү педагогның информацион культурасы үсүенең төп чыганагына әверелә. Ә ул үз чиратында үзбелемнең үсүенә һәм инновацион процессларның тизләнүенә сәбәпче була [Юзмиева С.Г.: 2015].

Тел һәм әдәбият дәресләрендә электрон кушымталар куллану укыту процессы алдында торган бер төркем бурычларны хәл итү мөмкинлекләрен ача: яңа материалны өйрәнү; үтелгән мате-

риалны кабатлау; белемнәрне һәм күнекмәләрне камилләштерү, белемнәр һәм күнекмәләрне практикада куллану; белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру. Электрон кушымталарда һәрвакыт диярлек аудио һәм видеофайллар кертелә, бу, һичшиксез, зур плюс. Укучы алар ярдәмендә дөрес әйтелешне ишетә, орфоэпик яктан сөйләмен камилләштерә ала. Шулай ук электрон кушымталар мәктәп курсы буенча һәм аннан тыш, гомумән, укучының күзаллавын киңәйтә торган өстәмә материаллар кертү мөмкинлеген бирә. Уку процессы индивидуальләштерү бара, бу укытуның сыйфатына да уңай яктан тәэсир итә.

Яңа мәгълүмати технология барлыкка килгәнче үк, күп кенә экспериментлар үткәреп, экспертлар материалны үзләштерү методы һәм берникадәр вакыттан соң алган белемнәрне яңарту мөмкинлеге арасында бәйлелекне ачыклаганнар. Әгәр материал тавышлы булган икән, кеше мәгълүмат күләменең якынча 1\4 исендә калдыра. Әгәр мәгълүмат визуаль рәвештә бирелә икән, якынча 1\3 хәтердә кала. Тәэсир итү методлары кушылган очракта (визуаль һәм тавыш), материалның якынча яртысына кадәр истә калдырыла, ә өйрәнү барышында кеше актив эшчәнлеккә җәлеп ителә икән, материалны үзләштерү 75% кадәр җитә.

Укыту процессында актив эшчәнлеккә тарту мультимедиалы кушымталар нигезендә ята. Мәсәлән, И.Х.Мияссарова, Ф.Ш.Гарифуллина, Р.Р.Шамсутдинова авторлыгындагы «Әлифба» дәреслегенә ясалган электрон кушымтада биремнәр уен рәвешендә бирелә. Күпмедер дәрәҗәдә бу тренировка өчен программа, ягъни ул күнекмәләрне камилләштерү мөмкинлеген бирә. Нәкъ шушы максатта, укытучы әлеге кушымтаны теләсә кайсы дәрестә куллана ала, аерым бер өлешләре өйгә эш буларак бирелә ала. Үтелгән материалны укучы өйдә үзлектән кабатлый ала, биремнәрне мөстәкыйль рәвештә эшләргә мөмкин, аларны эшләү алгоритмы шактый гади.

Туган тел дәресләрендә кулланыла торган электрон кушымталарның башка типтагылары да очрый (тикшерү төрки телләрне өйрәнү өлкәсендәге хезмәтләргә нигезләнер алып барылды). Мисал өчен, төрек теленә өйрәтә торган «Açılım Türkçe ders kitabı 1» карыйк. Әлеге программа конкрет дәреслеккә катгый бәйләнгән.

Мондый төр кушымталарны дәреслекнең электрон форматы дип тә атыйлар. Дәреслек битләре электрон форматка күчерелә һәм техник мөмкинлекләр, интерактив биремнәр, аудио һәм видеофайллар белән баетыла.

Төркиядә мәгълүмати-компьютер технологияләрен куллану алга киткән. Соңгы берничә дистә ел эчендә бу өлкәдә Төркиядә күп эшләр башкарыла. Төркия Мәгариф министрлыгы барлык укучыларны планшетлар белән тәэмин итә. Бу махсус «FATIH» проекты («Мөмкинлекләрне киңәйтү һәм технологияләрне яхшырту хәрәкәте») кысаларында башкарыла. Шулай ук әлеге проект кысаларында «Smart-класс»лар булдыру тормышка ашырыла. 42000 мәктәп һәм 570000 класс заманча мәгълүмати технологияләр белән тәэмин ителәчәк. Планшетлар, интерактив такталар белән җиһазланган класслар куллану укыту системасын камилләштерүгә этәргеч ясар, укучыларга материалны үзләштерүдә ярдәм итәр дип көтелә. Әлеге заманча җиһазларны дәрестә нәтиҗәле кулланырга өйрәтү максатыннан укытучылар өчен сервис-тренинглар уздырыла. Электрон укыту контентына кигәндә, ул кабул ителгән укыту программаларына нигезләнгән булырга тиеш [meb.gov.tr: 2015]. «FATIH» проектының 5 төп компонентын аерып карыйлар:

- җиһазлау һәм программа өлеше белән тәэмин итү;
- электрон укыту материаллары һәм электрон контент белән идарә итүне булдыру;
- укыту программаларында мәгълүмати-компьютер технологияләрен нәтиҗәле куллану;
- укытучыларны мәгълүмати-компьютер технологияләрен кулланырга өйрәтү;
- мәгълүмати-компьютер технологияләрен аңлап, ышанычлы һәм үлчәп куллану.

Төркиянең электрон ресурслары күбесенчә eba.gov.tr [eba.gov.tr: 2013]. социаль һәм белем бирү порталында тупланган. Монда төрле фәннәрдән 1687e-Kitap (электрон китап) урнаштырылган.

Шулай ук Төркиядә E-Okul (электрон мәктәп) проекты уңышлы эшләп килә. Укучыларның барлык эшләре электрон

форматта алып барыла һәм бөтен мәгълүмат махсус серверда саклана. Әти-әниләр e-okul.meb.gov.tr [e-okul.meb.gov.tr: 2007] сайтына кереп, расписание, укытучыларның искәрмәләрен, төрле фәннәрдән, шулай ук тәртип өчен куелган билгеләрне, дәрес калдыруларны, контроль эшләрнең датасын һәм нәтиҗәләрен һәм башка мәгълүматларны карый ала. Системага керү өчен, укучының шәхес таныклыгы номерын һәм мәктәптә бирелгән махсус номерны кертергә кирәк. Әлеге система мобиль телефоннарда да кулланыла башлады. Барлык мәгълүмат ата-ананың телефонына җибәрелә. Әлеге мөмкинлекләр Татарстанда да актив кулланыла. Мәгариф системасын информатизацияләү өлкәсендә Татарстан Республикасы – Россиядә алдынгы регионнарның берсе.

Электрон кушымталарны куллану соңгы елларда Азербайҗанда активлашып китте. Бу илдә үткәрелә торган сәясәт белән бәйләнгән. Мәгариф системасын модернизацияләнә, халыкара тәҗрибәне өйрәнелеп, техник казанышлар, мәгълүмати-компьютер технологияләре актив кулланыла. Азербайҗан Республикасында гомуми белем бирү системасында дәреслекләр буенча махсус сәясәт алып барыла. Әлеге сәясәтне тормышка ашырганда Азербайҗан Республикасы Конституциясе, Мәгариф турындагы канун, махсус актлар нигез итеп алына. Азербайҗан Республикасы мәгариф министрлыгы сайтында урнаштырылган махсус документ та бар. Ул «Гомуми белем бирү системасында дәреслекләр буенча сәясәт» дип атала. Әлеге документның 9 нчы пунктында электрон дәреслекләрне куллану турында сүз бара. Анда «Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган электрон дәреслекләр һәм уку әсбаплары мәктәпләрдә кулланыла ала» диелгән [Политика по учебникам в системе общего образования: 2009].

«Азербайҗан Республикасында Мәгарифне үстерү буенча дәүләт Стратегиясе»нең (Азербайҗан Республикасы Президентының 2013 елның 24 октябрендәге боерыгында расланган) әһәмиятле бурычларының берсе – укыту процессында заманча мәгълүмати технологияләрне куллану. Бу тизләтелгән темплар белән һәм халыкара тәҗрибәне кулланып башкарылырга тиеш. Стратегиядә мәгълүмати технологияләрне мәгаиф системасына кертүнең түбәндәге юнәлешләре билгеләнгән:

– Мәгълүмати-коммуникатив технологияләргә нигезләнгән яңа куррикулум (куррикулум – укыту процессы белән бәйле булган эшчәнлекне эффектив оештыру, максатчан һәм дәвамлы тормышка ашыру мөмкинлеге бирә торган концептуаль документ) һәм укыту методологияләренә туры китереп методик әсбаплар, дидактик материаллар һәм укыту әсбаплары әзерләүне стимуллаштыручы яңа механизмнарны булдыру;

– уку йортларында мәгълүмати-коммуникатив технологияләргә нигезләнгән укыту методологияләре таләпләренә туры килгән инфраструктура булдыру; һәрбер уку йортын Интернет белән тәэмин итү, ә гомуми урта белем бирү дәрәҗәсендә һәрбер укучыны электрон пособиеләр урнаштырылган компьютер-планшет белән тәэмин итү;

– мәгариф белән бәйле мәгълүмати һәм Интернет ресурслар үсешен тэмин итү;

– дистанцион уку, сәләтле балалар һәм махсус ярдәм таләп ителә торган балалар, өлкән яшьтәге кешеләрне укыту, профессиональ белем бирү һәм башка сораулар буенча консультацион хезмәт күрсәтүче региональ универсаль үзәкләр булдыру.

Электрон ресурсларны бер чыганакта урнаштыру өчен анда www.e-resurs.edu.az адресы буенча урнашкан махсус портал да булдырылды. Әлеге порталга кереп электрон дәреслекләр, видеодәресләр, конкурслар, биремнәр һәм башка электрон ресурслар белән кулланырга мөмкин. Әлеге порталда урнаштырылган дәреслекләрнең күбесен электрон форматтагы дәреслекләр дип атарга була. Аларда интерактивлык бик аз. Интерактив уеннар порталның аерым рубрикасына чыгарылган. «Intellektual oyunlar (интерактив уеннар) укытучы төрле дәресләрдә куллана ала. Ләкин бу укытучыдан алдан әзерлек эше таләп итә, ул барлык уеннарны карап чыгарга һәм аларны дәрестә куллануны планлаштырырга тиеш. Электрон форматтагы дәреслекләрдә кайсы темага, кагыйдәгә караган интерактив уеннар булуы турында мәгълүмат юк. Шулай ук махсус адаптацияләнгән программалы дәреслекләр дә урнаштырылган. Мәсәлән, «Əlifba» электрон дәреслеге «Eşitməsində çətinliyi olan uşaqlar üçün dərslik» буларак билгеләнгән, ягъни начар ишетүче балалар өчен махсус эшләнгән. Пор-

талда урнаштырылган электрон ресурслардан тыш, азербәйҗан теленә өйрәтә торган башка мультимедиале кушымталар да шактый. Мәсәлән, Talk Now! Learn Azeri (2004 год), BYKI Deluxe 3.6 – Azerbaijani (2009) шундыйлардан. Алар лексиканы өйрәнүгә юнәлгән. Монда сүзләрне, аларның язылышын, дөрес әйтелешен истә калдыруга юнәлгән күпсанлы интерактив уеннар урнаштырылган. Әлеге программаларның элементлары инглиз телен өйрәтүче бүгенге көндә популяр LinguaLeo программасының аерым бер өлешләренә охшаш. Мондый төр электрон кушымталар мәктәп программасы белән бәйләнмәгән, алар телне яңа өйрәнә башлаучыларны күздә тотып эшләнә. Әлеге электрон кушымталарда азербәйҗан теленә башка тел аша өйрәтү бара. Азербәйҗан-инглиз, азербәйҗан-рус вариацияләре очрый.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, төрле электрон кушымталарны укыту процессында куллануның укучылар сәламәтлегенә ничек тәэсир итүе әлегә кадәр җентекләп өйрәнелмәгән. Төгәл санитар таләпләр эшләнмәгән. Электрон технологияләрнең укыту процессына зур тизлек белән үтеп керүен искә алсак, аларның сәламәтлеккә йогынтысы тиздән тикшерү объектына әйләнәчәк.

Бүгенге көндә басма дәреслекләрнең өлешчә электрон форматтагыларга алыштыру, ә төгәлрәге аларны параллель куллану турында сүз бара. Ләкин укыту процессының үзәгендә укытучы кала һәм калачак та, калганы икенчел һәм ярдәм ролен генә башкара. Киләчәктә техник мөмкинлекләре киңәйтелгән мөстәкыйль электрон дәреслекләр эшләнгән очракта да, алар белән эш укытучы күзәтүе астында һәм аның аңлатмалары, шәрехләре белән үрелеп барырга тиеш. Укучылар өчен төп белем чыганагы булып һәрвакыт укытучы калачак.

## 3. МӘКТӘП ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНӘ ЭЛЕКТРОН КУШЫМТАЛАР

Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләренә электрон кушымталар эзерләү өлкәсендә эшчәнлек соңгы елларда шактый активлашса да мондый төр әсбаплар әзерләү өлкәсендә бу әле беренче адымнар гына, шуңа күрә без башка төрки телләр тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итәргә булдык. Төрек теленнән электрон кушымталар ясау өлкәсендә күптәннән актив һәм продуктив эш алып барыла. Шуңа күрә тикшерүебезнең объекты буларак төрек телендәге «Açılım Türkçe ders kitabı 1» электрон кушымтасы сайлап алынды. Азербәйҗанда соңгы елларда электрон кушымталар куллану шактый активлашып китүен искә алып, тикшерүебезнең тагын бер объекты буларак «Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасы сайланды. Чагыштырма анализ үткәрү өчен И.Х.Мияссарова, Ф.Ш.Гарифуллина, Р.Р.Шамсутдинова авторлыгындагы «Әлифба» дәреслегенә ясалган электрон кушымтага тукталдык (алга таба «Әлифба» дип кулланганда, әлеге басма дәреслекнең электрон кушымтасы хакында сүз барачак). «Әлифба» татар телендә белем алучы укучыларга юнәлгән, шуңа да тулысынча татар телендә. «Azərbaycan dili 2-ci sinif» та тулысы белән азербәйҗан телендә. «Açılım Türkçe ders kitabı 1»дә без төрек һәм инглиз теле белән очрашабыз. Дәреслек телне яңа өйрәнә башлаучыларга дип билгеләнгән.

«Açılım Türkçe ders kitabı 1»ның фәнни консультантлары: Prof. Dr. Murat Özbay һәм Doç. Dr. Hüseyin Özcan.

«Azərbaycan dili 2-ci sinif» дәреслегенең авторлары Rafiq İsmayılov, Gülşən Orucova, Zahid Xəlilov, Dilrüba Cəfərova.

### 3.1 Программа өлеше

«Әлифба» һәм «Açılım Türkçe ders kitabı 1» электрон кушымталарның икесе дә Adobe Flash программасы ярдәмендә эшләнгән. Adobe Flash – Adobe Systems компаниясенең веб-кушымталар яки мультимедиале презентацияләр ясау өчен кулланыла торган мультимедиале платформасы. Реклама баннерлары, анимация, уеннар ясау, шулай ук веб-битләрдә видео һәм аудиофайлларны уйнату өчен киң кулланыла. Flash-технологияләр

(еш кына аларны интерактив веб-анимация технологияләре дип тә атыйлар) Macromedia компаниясе тарафыннан эшләп чыгарыла һәм мәгълүматны мультимедиале рәвештә җиткерү өлкәсендәге күпсанлы технологик мөмкинлекләрне үз эченә туплый. Flash программаларның төп инструменты буларак вектор графикасын куллану мультимедианең нигезен тәшкил иткән элементларны (хәрәкәт, тавыш һәм объектлар интерактивлыгы) тормышка ашыру мөмкинлеген бирә. Шул ук вакытта килеп чыккан программа үлчәме минималь һәм кулланучының экран үлчәменә бәйләнмәгән. Бу, үз чиратында, Интернет проектларга карата куелган таләпләрнең берсе [Власов А.И.: 2001]. Ләкин Flash ярдәмендә ясалган кушымталарның кимчелекләре дә шактый.

1. Flash программа карала торган компьютерның ресурсларына карата шактый югары таләпләр куела. Әлеге программаны уйнату процессорның шактый күп ресурсларын ала, ә уйнату тизлеге экран размерларына бәйләнгән. Шулай да, программа Windows операцион системасының төрле версияләре куелган теләсә кайсы компьютерда эшли, оператив хәтер, процессор тибы буенча кискен таләпләр куелмый. Бердәнбер аерма эш тизлеге булачак.

2. Хаталар тиешле дәрәҗәдә контрольдә тотылмый, бу үз чиратында кушымтаның еш кына эштән туктавына, ә кайвакыт, тулысынча браузерның эшен туктатуга китерә. Браузерның эшенә комачаулау мөмкинлеге булганы өчен, Flash кушымталар браузерларны эшләп чыгаручылар тарафыннан тәнкыйть утына тотыла.

3. Flash кушымтаны уйнату мөмкинлеге һәрвакыт булмаска яки бу шактый кыенлыклар тудырырга мөмкин. Күп вакытта кулланучылар үзләре, ә мәктәптә куллану очрагын карасак, администраторлар браузерларның көйләгечләрендә flash контентын сүндереп куялар. Бу система ресурсларын экономияләү, рекламадан котылу һәм мәгълүмати куркынычсызлык белән бәйле рәвештә эшләнә.

4. Текст рәвешендә бирелгән мәгълүмат Flash ярдәмендә куелган очракта, эзләү системаларына аны индексацияләү авырлаша.

Flash ярдәмендә программалаштырылган код, гадәттә, «яшерелгән» була, ягъни гади кулланучы аны ачып карый, таныша алмый (рәсем 1).




Рәсем 1. Flash ярдәмендә
программалаштырылган кодның мисалы

«Әлифба» һәм «Açılım Türkçe ders kitabı 1» бер программа ярдәмендә эшләнгән, димәк, техник яктан мөмкинлекләр якынча бертөсле дип карарга була. Техник таләпләр дә бертөсле. Ләкин төрек теле дәреслегенә электрон кушымта «Әлифба»га эшләнгән электрон кушымтадан беренче карашка ук шактый аерыла. Авторлар ике төрле юл белән киткәннәр. «Әлифба» дәреслегенә электрон кушымтада дәреслек, төгәлрәге үтелә торган грамматик материал, темалар, лексика нигез итеп алынган һәм яңа биремнәр эшләнгән. Төрек теле дәреслеге тулысы белән үзгәртелмичә кулланылган, ягъни безнең алда дәреслек битләре электрон форматта һәм шул ук биремнәр электрон рәвештә эшләү мөмкинлеге, аудио, видео белән баетылган.

Без тикшерә торган кушымталарның өченчесе – «Azərbaycan dili 2-ci sinif» HTML5 форматында эшләнгән.

HTML (HyperText Markup Language) – веб-бит билгеләү теле. Аның төп бурычы челтәр буенча тапшырыла торган мәгълүматны укыла торган контентка интерпретацияләү. Нәкъ менә HTML ярдәмендә без Интернетны бүгенге рәвешендә күрәбез: матур, төсле, күпкырлы. HTML5 – соңгы камилләштерелгән версия.

Аңа кадәр Интернетта актив кулланылган форматлар HTML 4.01, XHTML 1.0 и XHTML. Практикада продуктлар төрле форматларның синтезы буларак эшләп чыгарыла иде. HTML5 үз эчендә HTML һәм XHTML синтаксик нормаларын берләштерүче формат буларак барлыкка килә. HTML5 эшләп чыгару максаты – мультимедиа технологияләрне куллану мөмкинлекләрен яхшырту һәм шул ук вакытта кодның җиңел укылышын саклап калу [bigfozzy.com: 2015].

HTML5 форматының коды Flash прграммасы кодыннан визуаль рәвештә үк шактый аерыла. HTML5 форматында эшләнгән программаның коды белән кулланучылар таныша ала. Гомумән, бу өлкәдә күпмедер дәрәҗәдә белеме булган кулланучылар, бу форматта эшләнгән һәр продукт, шул исәптән ачык кулланылыштагы сайтларның, кодларын ачып карый ала, бу сер түгел (рәсем 2).




Рәсем 2. «Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасы кодының бер өлеше

Азербайҗан телендәге электрон кушымталарны карау өчен башта www.e-resurs.edu.az порталында теркәлергә кирәк. «Azərbaycan dili 2-ci sinif» кушымтасын сайлап алгач, безгә өч төрле вариант тәкъдим ителә: 1) ePub форматында йөкләү (ePub

yüklə), 2) офлайн уку өчен йөкләү (oflayn oxumaq üçün yüklə), 3) онлайн уку (onlayn oxu).

Electronic Publication (ePub) – Цифрлы китапбасу халыкара ассоциациясе (International Digital Publishing Association) эшләп чыгарган электрон китаплар форматы. Әлеге формат электрон китаплар һәм басмаларны җитештерү өчен кирәк булган программа һәм аппарат белән тәэмин итүне берләштереп, цифрлы басманы бер файлда эшләп чыгару һәм тарату мөмкинлеген бирә [whyepub.ru: 2011]. ePub контейнеры ZIP-архивына XHTML, HTML яки PDF форматындагы тесктлар, басманың XML форатындагы тасвиры, папкаларда – графика (шул исәптән вектор графикасы (SVG), шрифтлар, стильләр таблицасы һ.б. урнаштырылган. Әлеге форматтагы файллар төрле үлчәмдәге экранлы компьютер җиһазларында яхшы укыла, ягъни аларны ноутбукларда, смартфоннарда, букридер һәм хәтта гади мобиль телефоннарда да ачып укырга мөмкин. Шушы мөмкинлекләре аркасында ePub бөтен дөньяда киң кулланылыш тапты. Электрон дәреслекләрне эшләүчеләр һәм дистрибьюторлар бүген аңа еш мөрәҗәгать итә, соңгы берничә елда аның популярлыгы тагын да артты. «Azərbaycan dili 2-ci sinif» кушымтасын ePub форматында компьютерыбызга йөклибез икән, аны ачып уку өчен безгә махсус программа кирәк булачак. Әлеге форматны уку өчен таләп ителә торган программалар (ePub readerлар) бүген шактый күп һәм киң таралган, аларны табу авырлык тудырмый. Әгәр бу формат электрон китапка йөкләнә икән, бу очракта махсус программалар кирәк булмаячак, чөнки заманча электрон китапларның барысы да ePub форматын укый.

Офлайн уку өчен йөкләү кнопкасына бассак, әлеге кушымта безнең компьютерга (ноутбук, смартфон һ.б. җиһаз булырга мөмкин) папкалар архивы буларак сакланачак. Алга таба архивны ачу һәм baslat.html файлын җибәрү таләп ителә.

Онлайн уку өчен махсус программалар таләп ителми. Кулланучы турыдан-туры электрон дәреслекнең башлам битенә эләгә.

«Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасы белән эшләгәндә формат һәм режим сайлау мөмкинлеге бар. Бу, әлбәттә, әлеге электрон кушымтаның уңышлы ягы.

## 3.2 Структура

«Әлифба»да башлам (старт) бите – А хәрефенә караган материаллар (рәсем 3), «Açılım Türkçe ders kitabı 1»дә – дәреслекнең 4нче бите, эчтәлек (рәсем 4), «Azərbaycan dili 2-ci sinif»та – дәреслекнең титул бите, 1 нче бит (рәсем 5).




Рәсем 3. «Әлифба» дәреслегенә электрон кушымтаның башлам (старт) бите




Рәсем 4. «Açılım Türkçe ders kitabı 1» электрон кушымтасының башлам (старт) бите




Рәсем 5. «Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасының башлам (старт) бите

«Әлифба»да эш панеле өстә. Монда биш рубрикатор урнаштырылган: дәрескә материаллар, биремнәр, тыңлау, мультфильмнар, шартлы билгеләр. Сул якта тагын бер кнопка урнашкан, аңа баскач, алфавит чыга. Әлеге функция барлык рубрикаторларда да актив, ягъни һәрвакыт кирәкле хәрефкә күчү мөмкинлеге бар. Дәрестә укытучы кирәкле хәрефне сайлап алып уку планы буенча бара ала. Басма «Әлифба» дәреслегендә укучылар башта сузык авазларны өйрәнә. Дәрестә үтелгән материалларны электрон кушымта ярдәмендә өйдә кабатлый ала. Биремнәрне эшләү алгоритмы шактый гади, аларны беренче сыйныф укучысы да мөстәкыйль рәвештә эшли ала.

Төзелеш структурасына нигез итеп татар алфавиты алынган. Һәр хәрефкә дәрескә материаллар, биремнәр һәм тыңлау күнегүләре (аудиоматериаллар) бирелгән. Дәрескә материалларда күнегүләр ярдәмендә ныгытыла торган дидактик материаллар (хәреф, аның төрле позицияләрдә кулланышы, матур язу һәм дөрес әйтелеш үрнәкләре) бирелгән. Визуаль рәвештә дәрескә материаллар рубрикасында без өч бүленешне күрәбез.

1. Хәреф, әлеге хәреф кулланылган сүзләр, аларның дөрес әйтелешен тыңлау өчен сүз янындагы динамик төшерелгән шартлы рәсемгә басарга кирәк.

2. Хәрефне матур язу үрнәге анимация рәвешендә бирелгән. Монда ике шартлы рәсем күрәбез. Аларның берсе ярдәмендә анимацияне башлап җибәрергә, икенчесе ярдәмендә туктатырга мөмкин.

3. Хәреф белдергән аваз. Динамик төшерелгән шартлы рәсемгә басып әлеге хәрефнең нинди аваз яки авазлар белдерүен тыңлап үтәргә була.

Төрек теле дәреслегенә электрон кушымтаның («Açılım Türkçe ders kitabı 1») эш панеле уң якта урнашкан. Монда башлам битенә кайту ; ябу ; битләрне алга һәм артка күчерү ; бит саны (бит санын клавиатура ярдәмендә кертеп, «sayfaya git» кнопкасына басып та кирәкле биткә күчү функциясе каралган) ; текстның аерым бер өлешен генә ачу ; текстны тулысынча ябып, аны өстән, астан, сулдан һәм уңнан ачу ; текстны зурайту/кечерәйтү ; язу панеле .

«Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасының эш панеле шулай ук уң якта урнашкан. Иң өстә кушымтаның исеме белән бер юлда ике кнопка урнашкан. Сорау билгесе ясалган кнопкага басып, кушымтада кулланылган барлык кнопкалар һәм шартлы билгеләрнең аңлатмаларын күрергә мөмкин. Әлеге порталга урнаштырылган электрон дәреслекләрнең структурасы бертөсле, шуңа да аңлатма битендә мәгълүмат 6 сыйныф Физика дәреслеге үрнәгендә күрсәтелә (рәсем 6). Өстәге панельдәге икенче кнопка – ябу . Алга таба уң якта бераз астарак төп эш панеле урнашкан.

1. Темалар (Mövzular)
2. Битләр (Səhifələr)
3. Искәрмәләр кертү (Qeydlər aparmaq)
4. Эзләү (Axtariş)

5. Сайланмалар (Seçilmişlər) 
6. Статистика (Statistika) 




Рәсем 6. «Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасында 6 сыйныф Физика дәреслеге үрнәгендә аңлатма

Уң яктагы эш панеле астында барлык битләр саны күрсәтелгән. Бу дәреслектә 208 бит. Уртада хәзерге моментта кулланучының кайсы биттә булуы күрсәтелә. Әлеге күрсәткеч янындагы укка бассак, битләр нумерациясе чыга һәм кирәкле битне сайлап, аңа күчәргә мөмкин. Уңайлылык өчен монда вертикаль скроллинг (әйләндерү) урнаштырылган. Алга һәм артка күчү өчен, төп контент янында ике зур ук урнаштырылган. Аларга басып, бер биткә алга яки артка күчәргә мөмкин. Ләкин әлеге функцияне кулланганда кайвакыт программа өлешендәге хата белән очрашабыз, «Not Found. The requested URL /undefined was not found on this server» хәбәре чыга. Программа битне югалта, серверда мондый бит бөтенләй табылмады дигән мәгълүмат бирә. Программистлар тарафыннан мондый баглар (хаталар) төзәтелергә тиеш, еш кына алар программа апробация үткәндә кулланылучылар тарафыннан табыла. Вертикаль скроллинг дәреслек битен тулысынча ачу, «Темалар» һәм «Битләр» рубрикаларында да кулланыла.

«Статистика» рубрикасында барлыгы ничә бит булуы, аларның ничәсе каралганлыгы һәм тагын ничә бит карыйсы калганлыгы күрсәтелә (рәсем 7).




Рәсем 7. «Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасының «статистика» рубрикасы

### 3.3. Биремнәр

Биремнәр «Әлифба» дәреслегенең нигезен тәшкил итә торган аваз-хәреф анализы күнекмәсен ныгытуга юнәлгән. Биремнәрдә укучыларның яшь үзенчәлекләре истә тотылган. Укыту уен аша бирелә. Биремнәрдәге уеннар яңа материалны үзләштерү һәм үтелгәннәрне ныгытуның бер этабы булып тора. Карандаш персонажы кертелгән, дөрес җавап өчен мактый 

, ә укучы ялгышса, кабат уйларга чакыра 

. Укучы ха-

тасын табып төзәтә ала. «Açılım Türkçe ders kitabı 1»дә бәяләү төрек телендә бирелә. Моның өчен аерым персонаж кертелмәгән, бу аңлашыла да, чөнки бу очракта яшь үзенчәлекләре моны таләп итми. Бәяләү «biraz daha dikkat» (бераз күбрәк игътибар), «üzgünüm» (кызганыч), «süpersin» (син – супер!), «çok iyi» (бик яхшы) һ.б. фразалар ярдәмендә башкарыла. Биремнәр һәм эш төрләрен берничә төргә бүлеп карарга мөмкин: 1) тавыш (ses)  2) рәсем (resim)  3) эшчәнлек (etkinlik) . Без тикшергән электрон кушымталарның икесендә дә биремнәрдә, программа өлешенә игътибар итсәк, random функциясе кулланыла, ягъни уенны яңадан башлаганда җавапларның урынннары, төсләре, рәсемнәр, хәрефләр һ.б. очраклы рәвештә үзгәрә. Укучы һәрвакыт уйларга тиеш.

«Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасында интерактив биремнәр юк. Интеракитив уеннар (Intellektual oyunlar) порталның аерым рубрикасына чыгарылган. Хәзерге вакытта порталга тарих һәм география фәннәреннән уеннар урнаштырылган. Шуңа күрә әлеге электрон кушымтада бәяләүче персонаж да, бәяләү фразалары да юк. Кушымта белән эш барышында исә, компьютер лексикасына хас нейтраль, эмоциональ бизәге булмаган фразалар белән очрашабыз: «Nəticə tapılmadı» (нәтиҗә табылмады), «Xahiş edirik not daxil edin» (искәрмә кертелмәде) һ.б.

Электрон кушымталардагы биремнәрне классификацияләп карыйк. «Әлифба»ның биремнәрен түбәндәгечә төркемнәргә мөмкин.

1. Авазның сүз башы позициясен аера белергә өйрәтүче биремнәр. Бирелгән авазга башланган яки әлеге аваз кергән сүзләрнең рәсемнәрен сайлап алу. Әлеге төр бирем сузык авазлар өчен бирелгән. Алда әйтелгәнчә, уку программасы нигезендә, башта сузык авазлар өйрәнелә, укучылар әле укый белми, шуңа күрә авторлар сүзләрнең рәсемнәрен кулланган, күрәсең. Безнеңчә, әлеге төр биремнәрдә рәсемнәр астына сүзләрнең үзләрен язу да шактый уңышлы булыр иде. Бу очракта укучы сүзнең язылышына да игътибар итеп, өйрәнгән хәрефнең төрле позицияләрдә кулланылышын тагын бер тапкыр ныгытыр иде.

2. Сүзләрне иҗекләргә дөрес итеп бүлү күнекмәсен булдыруга юнәлгән биремнәр. Бу төр биремнәр уен формасында бирелгән. Укучы өч поезд арасыннан сайлап ала, дөрес сайланган очракта поезд сигнал биреп кузгалып китә (рәсем 8).




Рәсем 8. «Әлифба» электрон кушымтасында иҗекләргә дөрес бүленешне кабатлау өчен бирем

3. Авазларның сүздәге позициясен билгеләргә, яңа сүзләр ясарга өйрәнү өчен биремнәр. Мәсәлән: хәреф өстәп яңа сүз ясау; сүзләрнең хәрефен үзгәртеп яңа сүз ясау; кушылмаларга нигезләнеп сүзләр ясау һ.б.

4. Калын һәм нечкә сузыкларны аера белү күнекмәсен булдыруга юнәлгән биремнәр: сүздәге калын сузыкны нечкә пары белән алмаштырып сүз ясау; калын һәм нечкә әйтелешле авазларны табу; кушылмаларның калын һәм нечкә парларын табу; хәрефләрне чиратлаштырып сүзләр ясау һ.б.

5. Укучының лексик байлыгын арттыруга юнәлгән күнегүләр дә шактый: бирелгән сүз эчендә яшерелгән сүзләрне эзләү, яңа сүзләр ясауга бәйле биремнәрне дә бу төркемгә кертеп карарга мөмкин.

6. Орфографиягә караган биремнәр: төшеп калган хәрефләрне урынына куй; кайсы сүзләрдә нечкәлек билгесе куела һ.б.

7. Татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнү, тәрҗемә итү күнекмәсе булдыруга юнәлгән күнегүләр: сүзләрнең рус теленә тәрҗемәсен яз.

8. Текст белән эшләү күнекмәсе булдыруга юнәлгән биремнәр: төшеп калган сүзне тап һәм урынына куй һ.б. Аудио файллар белән эшләү дә бу максатка хезмәт итә. Яңа сүзләр, катлаулы лексикага монда аңлатма бирелеп бара. Текстларны диктор орфоэпия кагыйдәләренә туры китереп укый, дөрес интонацион бүленешләр текстны кабул итү һәм аңлауны җиңеләйтә.

9. «Әлифба»ның басма дәреслегендә укучылар сүзләрне схемаларда күрсәтергә өйрәнә. Электрон кушымтада да схема белән эшләү дәвам итә. Бу очракта, «сүзләрне схемаларда күрсәт» тибындагы күнегүләр дәрестә үтелгән материлны кабатлау булып тора. Схемада күрсәтүне автоматик рәвешкә җиткерүгә ярдәм итә, бу күнегүләр тренировка тибында бара.

«Açılım Türkçe ders kitabı 1»дәге биремнәрне түбәндәге төркемнәргә аерып чыгарырга була.

1. Биремнәр күбесе аудиофайллар белән бирелә һәм ишетеп аңлауга, дөрес әйтелешне өйрәнүгә юнәлгән: тыңла һәм кабатла; кара һәм тыңла; тыңлагыз һәм тиешле номерлар куегыз; тыңлагыз һәм языгыз һ.б.

2. Текст белән эшләүгә юнәлгән күнегүләрнең кайберсендә тыңлап эшләү биремгә чыгарылмаса да, аудио файл бирелә, мондый очракларда аудио биремне башкарып чыккач, тикшереп карау өчен бирелә. Мәсәлән: укы һәм яз; диалогларны укыгыз; диалогны дәвам ит.

3. Коммуникатив технологиягә нигезләнгән күнегүләр. Сөйләм үстерү, диалоглар белән эшләү күз алдында тотыла: яңа диалог төзегез; диалогны дәвам итегез һ.б.

4. Алфавитны өйрәтү максатыннан кертелгән күнегүләр дә бар: юл хәрефләрен языгыз.

5. Укучыларга хата эзләтүгә юнәлгән биремнәр: хаталарны табып төзәтегез; дөрес җавапны билгелә; дөрес һәм ялгышны билгелә.

6. Уен формасындагы биремнәр дә очрый, ләкин алар чагыштырмача аз. Мәсәлән, шундыйларның берсе – тәңгәлләштерү (рәсем 9).




Рәсем 9. «Açılım Türkçe ders kitabı 1» электрон кушымтасында тәңгәлләштерүгә нигезләнгән уеннар

Сүзләрнең, фразаларның логик яки грамматик яктан тәңгәл килгән парларын табып, аларны тоташтыру. Мондый төр уеннарда биремне чишүгә сарыф ителгән вакыт һәм ясалган хаталар санала (рәсем 10). Уенга кабат кергән очракта, моңа кадәр үтелгән соңгы уенның нәтиҗәләре күрсәтелә.




Рәсем 10. «Açılım Türkçe ders kitabı 1» электрон кушымтасында тәңгәлләштерүгә нигезләнгән уеннарда вакыт күрсәткече

7. Аерым бер биремнәр укучылар көндәлек тормышта ярытып башкара торган уеннар рәвешендә бирелгән: кроссвордны чиш; яшерелгән сүзләрне тап. Яшерелгән сүзләрне табу биреме без алда караган «Әлифба»да да бар. Ләкин аларның бирелеш формасы төрле. «Әлифба»да бирелгән бер озын сүз эченнән яшерелгән сүзләрне эзләргә кирәк булса (рәсем 11), «Açılım Türkçe ders kitabı 1»дә хәрефләр өеме эчендә вертикаль, горизонталь һәм диагональ буенча яшерелгән сүзләрне табарга кирәк (рәсем 12). «Әлифба»да сүзләр бирелмәгән, укучы аларны үзе эзләп табарга тиеш, төрек теленә өйрәтүче кушымтада уң якта эзләп табылырга тиешле сүзләр исемлеге бирелгән.

8. Җөмләдәге сүзләр тәртибен истә калдыру өчен махсус күнегүләр кертелгән: җөмләдәге сүзләрне дөрес тәртиптә урнаштырыгыз.Алар тренажёр формасында һәм шактый күп. Бу, безнеңчә, уңышлы форма бу очракта күп һәм төрле вариантларны кабатлап, укучы үзе системаны ачыклауга килә, ягъни бу очракта индуктив метод кулланыла.

9. Грамматиканы өйрәтү өчен махсус бүлек кертелгән, алар dil bilgisi (грамматика) дип атала. Монда күпчелек мәгълүмат схемалар, таблицалар рәвешендә урнаштырыла.

10. Контроль тикшерү биремнәре дә, тема үтелеп беткәч, аерым бер бүлек буларак кертелә.

11. Ахырда зур бер таблицага Төркиядә кулланыла торган кеше исемнәре урнаштырылган. Моны да зур плюс буларак билгеләп үтәргә кирәк. Әлеге мәгълүмат укучыларның күзаллавын киңәйтә.

Биремнәр башта төрек телендә, астында кечерәк шрифт белән инглиз телендә бирелә. «Әлифба»да биремнәр барысы да татар телендә бирелә. Ләкин биремнәрнең тексты белән танышу өчен укучыга укытучы яки әти-әнисе ярдәме кирәк булачак, чөнки ул әле укырга өйрәнә генә. Практика күрсәткәнчә, уен формасында бирелгән мондый биремнәрне укучылар тиз истә калдыра, берничә кабатлаудан соң алар электрон кушымта белән инде үзлектән дә эшли алалар.

«Açılım Türkçe ders kitabı 1»дә биремнәр шактый төрле. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, программистлар интерактив такта белән эшләүне дә күздә тотканнар. Моңа аерым игътибар бирелгәнен күрәбез. Электрон маркер ярдәмендә текстның




Рәсем 11. «Әлифба» электрон кушымтасында яшерелгән сүзләрне эзләү өчен бирем




Рәсем 12. «Açılım Türkçe ders kitabı 1» электрон кушымтасында яшерелгән сүзләрне эзләү өчен бирем

киракле өлешләрен төрле төсләр ярдәмендә билгеләү, шулай ук текстның кирәкле өлешен ябу/ ачу кебек функцияләр каралган.

«Açılım Türkçe ders kitabı 1» дәреслеге 112 биттә тукталып кала. Дәвамы «Açılım Türkçe ders kitabı 2»дә, дәреслекнең икенче өлеше. Ул нигездә шул ук принципларга таянып эшләнгән. Икенче CD дискка урнаштырылган.

«Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасының техник мөмкинлекләренә тукталып китик. Искәрмәләр кертү функциясе уңайлы эшләнгән. Кулланучы теләгән битен караганда, эш панелендә искәрмәләр функциясен сайлап, махсус билгеләнгән урынга фикерләрен терки һәм «Qeyd et» кнопкасына баса. Теркәлгән мәгълүмат әлеге бит белән бергә сакланып кала.

«Эзләү» функциясе дә кулланучыга уңай шартлар булдыру максатыннан, уйлап эшләнелгән. Кирәкле сүзне, сүзтезмәне, хәтта җөмләне дә кертеп, «эзләү»гә басабыз, һәм уң якта аерым баганада бөтен дәреслек буенча безне кызыксындырган нәтиҗәләр чыга. Әлеге сүз, сүзтезмә яки җөмлә кулланылган контексты белән бергә чыгарыла, кулланучы эзләгән элемент зуррак шрифт һәм кызыл төс белән билгеләнә. Кирәкле мәгълүмат шунда ук күзгә ташлана, игътибарны җәлеп итә. Табылган һәр нәтиҗәнең кайсы биттә булуы билгеләнгән, димәк, әгәр кулланучы үзен кызыксындырган мәгълүматны таба икән, ул шунда ук әлеге биткә күчеп, тагын да тулырак мәгълүмат белән таныша ала (рәсем 13).




Рәсем 13. «Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасында эзләү функциясе ярдәмендә табылган нәтиҗәләр үрәге

Электрон кушымталардагы материаллар һәм биремнәр укучының психик функцияләрен: хәтер, игътибар, уйлау, кабул итү, күзаллау һ.б. үстерүгә юнәлгән.

## 3.4 Медиафайллар

«Әлифба» һәм «Açılım Türkçe ders kitabı 1» электрон кушымталарның икесендә дә аудиоматериалларга аерым игътибар бирелә. Яңа лексика һәм грамматик материалның аудио файлы, тыңлап карау мөмкинлеге бар. Тел өйрәнүдә бу бик мөһим. «Әлифба»да аудиоматериаллар аерым рубрикага чыгарылган (рәсем 14).




Рәсем 14. «Әлифба» электрон кушымтасында аудиоматериал бирелеше мисалы

Дөрес әйтелешне ишетү, кабул итү телне өйрәнүнең һәр этабында әһәмияткә ия, ләкин башлангыч этапта бу аеруча мөһим. Монда тизәйткечләр, табышмаклар, шулай ук автор текстлары да урнаштырылган. Мондый төрлелек укучыларда кызыксынуны

арттыра. «Açılım Türkçe ders kitabı 1»дә һәр яңа тема башында бирелә торган күләмле текстның аудиосы юк. Бу мондый зур күләмле мәгълүматны кабул итүне шактый авырлаштыра. Текстлар Төркия тарихы, бүгенгесе, аның мәдәнияте һәм танылган шәхесләре турында. «Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымтасында аудиофайллар бөтенләй юк. Дәрес эйтелешне тыңлау, азербәйҗан теленең матур яңгырашы әлеге электрон басманы тулыландырыр, баетыр иде.

«Әлифба» һәм «Açılım Türkçe ders kitabı 1» электрон кушымталарының икесендә дә текстны яки аның кирәкле өлешен күчереп алу мөмкинлеге каралмаган. Бу, безнеңчә, кирәкле функция. «Azərbaycan dili 2-ci sinif»та әлеге функция каралган, текстларның теләсә кайсы җирен, сүзлекнең, биремнәрнең кирәкле өлешен сайлап, күчереп алырга мөмкин.

«Әлифба»да 27 мультфильм урнаштырылган (рәсем 15). «Açılım Türkçe ders kitabı 1»дә бик кызыклы һәм заманча эшләнгән 16 видеофайл бар (рәсем 16).




Рәсем 15. «Әлифба» электрон кушымтасына урнаштырылган мультфильмнар




Рәсем 16. «Açılım Türkçe ders kitabı 1» электрон кушымтасына урнаштырылган видеодан фрагмент

Без тикшергән электрон кушымталар барысы да иллюстрацияләргә бай. Дизайн, визуаль рәт электрон продуктларда шактый әһәмиятле роль уйный. «Açılım Türkçe ders kitabı 1» һәм «Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымталарында иллюстрацияләрне зурайтып карау мөмкинлеге эшләнгән. Бу функция интерактив такталар белән эшләгәндә аеруча кирәкле. Укытучы иллюстрацияләрне төрле биремнәр эшләтү, картина буенча инша яздыруда куллана ала.

«Açılım Türkçe ders kitabı 1»дә һәм «Azərbaycan dili 2-ci sinif»та безнең каршыда дәреслек битләре электрон форматта ачыла. Бу яктан ул Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы электрон дәреслекләргә карата куйган таләпләргә туры килә.

Без тикшергән кушымталар өчесе дә офлайн режимында эшли ала. «Әлифба» tatarschool.ru сайтында урнаштырылган.

Әлеге сайтка кереп, аны күчерергә мөмкин, шулай ук онлайн рәвештә эшләү мөмкинлеге дә бар. «Azərbaycan dili 2-ci sinif» шулай ук онлайн һәм офлайн режимнарында эшли. Ул e-resurs.edu.az сайтына урнаштыралган. «Açılım Türkçe ders kitabı 1» бездә CD форматында, бу очракта бары офлайн режимда эшләү хакында гына сүз бара.

Шулай итеп, «Açılım Türkçe ders kitabı 1» һәм «Azərbaycan dili 2-ci sinif» электрон кушымталарын электрон дәреслек, ә «Әлифба»ныкын мультимедияле кушымта дип классификацияләргә була. Безнеңчә, уку процессында бу ике төр электрон кушымталар бергә кулланылырга тиеш. Уку комплекты басма дәреслек, аның мөмкинлекләрен киңәйтә торган электрон дәреслек һәм укыту процессын кызыклы биремнәр, уеннар белән баета, өстәмә мәгълүмат бирә торган мультимедияле кушымтадан торырга мөмкин. Укыту процессын информатизацияләү өлкәсендә киләчәк соңгы икесенең интеграциясе буларак күзаллана. Укыту процессын информатизацияләү өлкәсендә киләчәк дәреслекнең электрон формасы һәм мультимедиалы кушымтаның тулы электрон дәреслеккә интеграциясе буларак күзаллана дигән фикергә килдек.

## 4. ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

XXI гасыр кешенең көндәлек тормышына информацион электрон технологияләрнең күпләп үтеп керүе белән башланып китте. Кәрәзле телефоннарга, электрон системалы көнкүреш машиналарына, компьютерларга хәзер беркем дә шаккатмый. Алар көндәлек кирәк-яраклары буларак кабул ителәләр. Яшәешебезне электрон технологияләр чолгап алган заманда, укучыларга белем бирү процессы да үзгәрешсез кала алмый.

Заман таләпләре татар телен, әдәбиятын укыту процессында да зур үзгәреш – уку-укыту процессында заманча укыту технологияләрне куллануны таләп итә. Безнең алда бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, телебезне саклап калу бурычы булса, икенчедән, рус телле балаларда телне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, бу кызыксынуны үстерү бурычы. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булу, иҗади эшчәнлекне таләп итә. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык – бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен, укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим. Тәҗрибә педагогик эшчәнлекнең нигезе булса, яңалыкка омтылу үсеш – үзгәрешне тәэмин итә. Бүген укытучы, иҗади шәхес буларак, күп укырга, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге яңалыклар белән таныш булырга гына түгел, ә заманча укыту методларының иң нәтиҗәлесен сайлап алып, үзләштереп эшли белергә дә тиеш. Бу исә белем бирүдә укытучыга түбәндәге мөһим бурычларны үтәргә ярдәм итә:

- рус телле укучыда телне чит тел буларак өйрәнүдә кызыксыну уяту;
- аның танып белү, эшчәнлек активлыгын үстерү;
- укучыларның иҗади мөмкинлекләрен камилләштерү;
- белемнәрне тирәнәйтү.

Заманча укыту алымнарын укыту-тәрбия эшендә гамәлгә ашыру укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән беррәттән укытуны заманча оештыра белүне дә таләп итә. Бу – заман-

ча укыту алымнарын нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты.

Белем бирүдә кулланыла торган информацион технологияләр берсен икенчесеннән аерып булмый торган ике өлештән тора:

1) техник чаралар (компьютер техникасы һәм шуңа бәйләнеш чаралары),

2) билгеле максатта кулланылган төрле программа чаралары.

Әгәр укытучы дәресне оештырганда компьютер кулланырга уйлый икән, ул югарыда әйтелгән чараларның мөмкинчелекләрен һәм куллану тәртибен белеп эш итәргә тиеш.

Ни өчен татар теле дәресләрендә компьютер техникасы куллану кирәк, яңа технология чаралары кулланып, дәрестә нинди мәсьәләләрне чишеп, хәл-итеп була соң?

Шушы сорауга җавап биреп карыйк. Беренчедән, укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну барлыкка килә. Балалар мәктәптә укытылган башка фәннәр арасында татар теле дәресләренең дә компьютер, Интернет кулланып өйрәнергә мөмкин икәнлеген күрәләр. Бу исә телнең абруен күтәрүдә зур этәргеч булып тора.

Икенчедән, мондый интерактив белем бирү чаралары баланың фикерләү сәләтен үстерә;

Өченчедән, эстетик тәрбия бирә.

Дүртенчедән, информацион культура тәрбияли;

Бишенчедән,укытуның сыйфатын күтәрә;

Алтынчыдан, предметара бәйләнеш булдыруга ярдәм итә;

Җиденчедән, укучыларда эзләнү-тикшеренү теләге уята.

Дәресләрдә информацион технологияләр укытучыга нинди методик мөмкинлекләр бирә?

Шуларны карап китик.

- дәрес материалы, тема ачык итеп күз алдына килә. Мәсәлән, “Кыш” темасына текстлар укыганда, укучыларның күз алдында кышкы табигать, карга күмелгән урамнар, кар көртләре баскан басу-кырлар, кар бөртекләре пәйда була;
- укучыга үз белемен үзе тикшерергә ярдәм итә. Тест формасындагы биремнәр нигезендә экранга карап үз-үзләрен тикшерәләр һәм үз эшләрен бәялиләр;

- индивидуаль белем бирү;
- дифференциаль белем бирү;
- мультимедиа һәм интернет аша зур күләмле мәгълүмат алырга өйрәтү;
- укыту процессында кирәк булган материалларны тупларга өйрәтү;

Татар теле һәм әдәбиятын укытуда заманча технологияләрне кулланунын әһәмияте, өстенлеге әнә шунда.

## ФАЙДАЛАНГАН ЧЫГАНАКЛАРҺӘМ ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Об образовании в Российской Федерации [Электронный ресурс] : федер. закон от 29 декабря 2012 г. № 273-ФЗ: (в ред. от 31 декабря 2014 с изм. от 06.04.2015 г. «Об образовании в Российской Федерации» (с изм. и доп., вступ. в силу с 31.03.2015) //consultant.ru: КонсультантПлюс: справ. правовая система. URL: http://www.consultant.ru/document/cons_doc_LAW_173649 (дата обращения: 2.04.2015).
2. Абросимов А.Г. Технологии дистанционного обучения в дополнительном образовании // Информатика и образование. – 2004. – № 7. – С. 77-83.
3. Абсеметова Ж. Методические принципы конструирования электронного учебника по истории Казахстана [Электронный ресурс] // hist.msu.ru: Исторический факультет Московского государственного университета имени М.В.Ломоносова // Конференции, проводимые на историческом факультете МГУ / VII конференция /доклады (теоретическая часть), 21.03.2001. URL: // http://www.hist.msu.ru/Association/HAC/aik/educat.htm (дата обращения: 12.01.2015).
4. Александров В.В., Булкин Г.А., Поляков А.О. Автоматизированная обработка информации на языке предикатов. АН СССР, Ленингр. н.-и. центр. М. : Наука, 1982. – 104 с.
5. Александров В.В. Интеллект и компьютер. СПб.: Издательство Анатолия, 2004. – 285 с.
6. Аллан Пайвио. Теория двойного кодирования и обучение [Электронный ресурс] // psychology-online.net: Материалы по психологии, 2011. URL: http://psychology-online.net/articles/doc-1743.html (дата обращения: 9.10.2014).
7. Алхазашвили Д.Н. Компьютерный учебник или медиатека? [Электронный ресурс] // hist.msu.ru Исторический факультет Московского государственного университета имени М.В.Ломоносова // Конференции, проводимые на историческом факультете МГУ / VII конференция /доклады (теоретическая часть), 21.03.2001. URL: http://www.hist.msu.ru/Association/HAC/aik/educat.htm (дата обращения: 12.01.2015).

8. Анисимова Н.С. Мультимедиа-технологии в образовании: понятия, методы, средства. – Санкт-Петербург: Изд-во РГПУ им. А.И. Герцена, 2002. – 90 с.
9. Анисимова Н.С. Методика построения управляющих сред мультимедийных обучающих комплексов. Санкт-Петербург: Изд-во РГПУ им. А.И. Герцена, 2002. – 91 с.
10. Антонов А.В. Информация: восприятие и понимание. Киев: Наук. думка,1988. – 184 с.
11. Әлифба [Электронный ресурс] // tatarschool.ru : Мультимедийные приложения к учебникам татарского языка, 2013. URL: // http://tatarschool.ru/al/index.html (дата обращения: 3.03.2014).
12. Баранова Ю.Ю. Методика использования электронных учебников в образовательном процессе // Информатика и образование. – 2000. – № 8. – С. 43-47.
13. Барболин М.П. Методологические основы развивающего обучения. М.: Высшая школа, 1991. – 280 с.
14. Бордовский Г.А. Кибернетический подход к информационным технологиям в непрерывном образовании. // Подготовка специалиста в области образования (структура и содержание). СПб.: Образование, 1994. – 237 с.
15. Бордовский Г.А., Извозчиков В.А., Слуцкий А.М., Тумалева Е.А. Электронно-коммуникативные средства, системы и технологии обучения. СПб.: Образование, 1995. – 167 с.
16. Бордовский Г.А., Носкова Т.А., Степанов А.А. Опыт дистантного аудиовизуального обучения в школах Северо-Западного региона. //Образование и культура Северо-Запада России – 1996. – № 1. – С.128-140.
17. Бордовский Г.А., Носкова Т.Н., Степанов А.А. Развивающие особенности аудиовизуальных технологий обучения // Педагогика. – 1996. – № 4. – С.10-15.
18. Бордовский Г.А., Носкова Т.Н. Модульная аудиовизуальная технология обучения перспектива современного урока // Наука и школа. – 1997. – № 6. – С.27-30.
19. Бордовский Г.А., Носкова Т.Н. Учебные видеоматериалы на урок // Народное образование. –1993. – № 4. – С.6-12.

20. Бороненко Т.А. Концепция школьного курса информатики: учеб. пособие: СПб: Высшая административная школа, 1995. – 68 с.
21. Братчиков И.Л., Марусева И.В., Казаков А.Ю. Теория и практика автоматизации учебного процесса. Ч. 1. Искусственный интеллект в обучении. Санкт-Петербург: Образование, 1993. – 52 с.
22. Величковский Б.М. Психология познания и кибернетика // Кибернетика живого: человек в разных аспектах. М.: Наука,1985. – С. 92-106
23. Величковский Б.М. Современная когнитивная психология. М.: Изд-во. Москов. гос. ун-та, 1982. – 336 с.
24. Власов А.И. Введение во flash-технологии [Электронный ресурс] // citforum.ru: форум программистов, 2001. URL: // http://citforum.ru/internet/flash_intro/index.shtml (дата обращения: 5.03.2015).
25. Воробьев В.И., Румянцев И.А., Соломин В.П. Информационная среда современной школы и задачи педагогического вуза в подготовке кадров. // Математика и информатика: педагогические инновации и научные разработки: Герценовские чтения 95. – СПб., 1995. – 160 с.
26. Гершунский Б.С. Компьютеризация в сфере образования. Проблемы и переспективы. – М.: Педагогика,1987. – 264 с.
27. Голицына И.Н. Эффективное управление учебной деятельностью с помощью компьютерных информационных технологий. // Education Technology & Society. – 2003. – № 6. – С. 77-83.
28. Гостев А.А. Образная сфера человека. – М.: Изд-во. Ин-та психологии РАН, 1992. – 196 с.
29. Горнова Н.В. Формирование готовности студентов к использованию информационных технологий в профессионально-педагогической деятельности. – Саратов: Сателлит, 2004. – 132 с.
30. Григорьев С.Г. Иерархические структуры как основа создания электронных средств обучения / С.Г. Григорьев, В.В. Гриншкун // Информатика и образование. – 2004. – № 7. – С. 96-98.

31. Гутгарц Р.Д. Компьютерная технология обучения / Р.Д. Гутгарц, В.П. Чебышева // Информатика и образование. – 2000. – № 5. – С. 44-45.
32. Давыдова Е.В. Создание Web-страниц с помощью языка электронная модель школьного учебника HTML // Информатика и образование. – 2000. – № 8. – С. 62-77.
33. Деревнина А.Ю. Расширение образовательного пространства регионального университета на основе информационных технологий // Открытое образование. – 2001. – № 6. – С. 47-49.
34. Дуайер Д. Apple-классы завтрашнего дня: чему мы научились / Пер. с англ. П. Гангнус // Информатика и образование. – 1995. – № 3. – С.110-115.
35. Дьяконова О.О. Эдьютейнмент в обучении иностранным языкам // Иностранные языки в школе – 2013 – № 3 – С.58-61
36. Ершов А.П. Компьютеризация школы и математическое образование. // Информатика и образование – № 5, 6. –1992. – С. 3–6.
37. Ершов А.П. О предмете информатики. // Вестник АН СССР. – 1984. – № 2. – С. 112-113.
38. Ершов А.П. Программирование – вторая грамотность. Новосибирск, 1981. – С. 18.
39. Ершов А.П., Звенигородский Г.А., Первин Ю.А. Школьная информатика (концепции, состояние, перспективы) // Информатика и образование. – 1995. – № 1. – С.9-10.
40. Жинкин Н.И. Речь как проводник информации. – М.: Наука, 1982. – 160 с.
41. Журбина Н.А. Информационно-коммуникационные технологии в образовании // Информационное общество. – 2001. – №2. – С. 5-6.
42. Зайнутдинова Л.Х. Создание и применение электронных учебников. Астрахань: ЦНТЭП, 1999. – 364 с.
43. Захарова И.Г. Информационные технологии в образовании: учебник. М.: Академия, 2003. – 192 с.
44. Зинченко П.И. Непроизвольное запоминание. – М.: Изд-во Акад. пед. наук РСФСР, 1961. – 562 с.

45. Иванов В.Л. Структура электронного учебника // Информатика и образование. – 2001. – № 6. – С. 12-15.
46. Извозчиков В.А. Инфоноосферная эдукология. Новые информационные технологии обучения. СПб., 1991. – 120 с.
47. Имаева Г.М. Татар теле дәресләрендә мәгълүмати технологияләрне куллану [Электронный ресурс] // conf.knitu.ru : VШ респуб. научно-методическая конференция педагогов общеобразовательных учреждений, преподавателей учреждений среднего и высшего профессионального образования «Интеграция школы и вуза как эффективный инструмент формирования актуальных компетенций учащихся» Казань, 2015. URL: // http://www.conf.knitu.ru/confkgtu/ru/conf_tez.jsp?id_conf=21&idm=3354&ff=%D0%E5%E3%E8%F1%F2%F0%E0%F6%E8%FF (дата обращения: 11.05.2015).
48. Информационные технологии в системе непрерывного педагогического образования / под ред. В.А.Извозчикова. – СПб.: Образование, 1996. – 222 с.
49. Казаков В.Е., Дорошкин А.А., Задорожный А.М., Князев Б.А. Лекционная мультимедиа аудитория // Информатика и образование. – 1995. – № 4. – С. 105-110
50. Казиев В.М. Информация: понятие, виды, получение, измерение и проблемы обучения // Информатика и образование. – 2000 – № 4. – С.12-23
51. Каймин В.А. От компьютерной грамотности к новой информационной культуре. // Сов. педагогика. – 1990. – № 4. – С. 70-71
52. Канаева В. М., Агапова С. Г. Из опыта творческой группы учителей по проблеме: компьютеризация учебного процесса в школе // Иностранные языки в школе. – 1992 – № 3-4 – С.86-88
53. Карамышева Т. В. Изучение иностранных языков с помощью компьютера. В вопросах и ответах. Спб.: Из-во «Союз», 2001. – 192 с.
54. Козлов О.А., Солодова Е.А. Некоторые аспекты создания и применения компьютеризованного учебника // Информатика и образование. – 1995. – № 3. – С. 97-99
55. Краснова Г.А. Технологии создания электронных обучающих средств. М.: Из-во Москов. гос. индустриал. ун-та, 2003. – 223 с.

56. Кривошеев А.О., Фомин С.С., Демушкин А.С. Компьютерные обучающие программы // Информатика и образование. – 1995. – № 3. – С. 15-22.
57. Кривошеев, А.О. Разработка и использование компьютерных обучающих программ: учебник // Информационные технологии. – 2001. – № 2. – С. 14-17.
58. Лаврентьев В.Н., Н.И. Пак Электронный учебник // Информатика и образование. – 2000. – № 9. – С. 87-91.
59. Ланина И.Я. Формирование познавательных интересов учащихся на уроках физики. М.: Просвещение, 1985. – 128 с.
60. Лаптев В.В., Швецкий М.В. Методическая система фундаментальной подготовки в области информатики: теория и практика многоуровневого педагогического университетского образования. Санкт-Петербург: Изд-во Санкт-Петербургского ун-та, 2000. – 508 с.
61. Лаптев В.В., Швецкий М.В. Метод демонстрационных примеров в обучении информатике студентов педагогичского вуза // Педагогическая информатика – 1994 – № 2. – С. 7-16.
62. Лапчик М. Информатика и технология: компоненты педагогического образования // Информатика и образование. – 1991 – № 6. – С.3-8.
63. Лапчик М. Информатика и технология: компоненты педагогического образования // Информатика и образование. – 1992 – № 1. – С.3-6.
64. Лернер И.Я. Дидактические основы методов обучения. М: Педагогика, 1981. – 184 с.
65. Лернер И.Я. Процесс обучения и его закономерности. М.: Знание, 1980. – 96 с.
66. Логвинов И.И., Логвинова Т.Л. Компьютерная грамотность в системе общего образования учащихся // Новые исследования в педагогических науках. – 1985. – № 2. – С. 30-33
67. Малюкова Г. Н., Соломахина И. А. Использование мультимедийных средств в обучении иностранному языку [Электронный ресурс] // festival.1september.ru: Фестиваль педагогический идей, 2013. URL: // http://festival.1september.ru/articles/212523/ (дата обращения: 11.10.2014).

68. Мануйлов В.Г. Введение в технологию разработки педагогических мультимедийных мастер-шаблонов // Информатика и образование. – 2001. – № 2. – С. 70-77
69. Матрос Д.Ш. Электронная модель школьного учебника // Информатика и образование. – 2000. – № 8. – С. 40-43
70. Макарова Н.В. Информатика: учебник. СПб.: Питер, 2004. – 300 с.
71. Машбиц Е.И. Компьютеризация обучения: проблемы и перспективы. М.: Знание, 1986. – 80 с.
72. Машбиц Е.И. Психолого-педагогические проблемы компьютеризации обучения. М.: Педагогика, 1988. – 192 с.
73. Мельников П.П. Технология разработки HTML-документов: учеб. пособие / Информатика и образование. – 2000. – № 10. – С. 15-18
74. Моисеев Н.Н. Стратегия разума // Знание и сила. – 1986. – №3. – С. 32-34
75. Монахов В.М. Психолого-педагогические проблемы обеспечения компьютерной грамотности учащихся // Вопросы психологии. – 1985. – № 3. – С. 14-22.
76. Наумов В.В. Разработка программных педагогических средств // Информатика и образование. – 1999. – № 3. – С. 36-40.
77. Николаенко Д.В. Практические занятия по JavaScript. СПб.: Наука и техника, 2000. – 128 с.
78. Нуруллина Л.Х. Использование современных инновационных подходов к преподаванию татарского языка и литературы [Электронный ресурс] // conf.knitu.ru : VШ респуб. научно-методическая конференция педагогов общеобразовательных учреждений, преподавателей учреждений среднего и высшего профессионального образования «Интеграция школы и вуза как эффективный инструмент формирования актуальных компетенций учащихся» Казань, 2015. URL: // http://www.conf.knitu.ru/confkgtu/ru/conf_tez.jsp?id_conf=21&idm=3354&ff=%D0%E5%E3%E8%F1%F2%F0%E0%F6%E8%FF (дата обращения: 11.05.2015).
79. Обухова Л.Ф. Концепция Ж. Пиаже: за и против. – М.: МГУ, 1981. – 191 с.

80. Пиаже Жан Избранные психологические труды. М.: Международная педагогическая академия, 1994. – 680 с.
81. Полат Е.С. Интернет в гуманитарном образовании: учебник. М.: Владос, 2001. – 272 с.
82. Политика по учебникам в системе общего образования [Электронный ресурс] // edu.gov.az: Министерство образования Азербайджанской Республики, 2009. URL: // http://www.edu.gov.az/view.php?lang=ru&menu=162&id=3194 (дата обращения: 10.05.2015).
83. Поспелов Д.А. Десять «горячих точек» в исследованиях по искусственному интеллекту // Интеллектуальные системы (МГУ). – Т.1, вып.1-4., 1996. – С.47-56.
84. Роберт И. Современные информационные технологии в образовании: дидактические проблемы; перспективы использования. – М.: Школа-Пресс, 1994. – 205 с.
85. Рош У.Л. Библия мультимедиа, пер. с англ. Киев: ДиаСофг, 1998. – 800 с.
86. Симонова И.В. Модели обучения практико-ориентированных учащихся в условиях развивающегося интернет-образования. СПб.: Изд-во СПбГТУ, 2000. – 99 с.
87. Симонова И.В. Гуманизация методической поддержки информатизации в районе. СПб.: Изд-во СПбГТУ, 2000. – 70 с.
88. Скибб Л.Д., Хэйфмейстер С., Чеснат А.М. Оптимизация мультимедиа ПК, пер. с англ. Киев: ДиаСофт, 1997. – 352 с.
89. Скибицкий Э.Г., Слуднов А.В. Идентификация педагогической целесообразности компьютерных технологий // Программные продукты и системы. – 1996. – № 1. – С. 23-28.
90. Соболева А.В. Использование мультимедийных технологий в обучении иностранным языкам // Педагогика: традиции и инновации: материалы IV междунар. науч. конф. г. Челябинск, декабрь, 2013 г. Челябинск: Два комсомольца, 2013. – С. 119–123.
91. Советов Б.Я. Теория информации. Теоретические основы передачи информации в АСУ. Л.: Изд-во Ленингр. ун-та, 1977. – 196 с.

92. Советов Б.Я., Рухман Е.Л., Яковлев С.А. Системы передачи информации от терминалов к ЦВМ. Л.: Изд-во Ленингр. ун-та, 1978. – 240 с.
93. Советов Б.Я., Яковлев С.А. Моделирование систем. М.: Высшая школа, 1985. – 271 с.
94. Соломин В. П. Гуманитарные технологии как инновация в образовании // Вестник ТГПУ. – 2011. – №4 – с. 124-127.
95. Талызина Н.Ф. Внедрение компьютеров в учебный процесс научную основу // Сов. педагогика. – 1985. – №12. – С. 34-38.
96. Тевелева С.В. Электронный учебник как средство дистанционного обучения // Информатика и образование. – 2000. – №8. – С. 48-51.
97. Уваров А.Ю. Электронный учебник: теория и практика. – М.: Изд-во УРАО, 1999. – 220 с.
98. Унт Н.Э. Индивидуализация и дифференциация обучения. М.: Педагогика, 1990. – 192 с.
99. Фролов А.В., Фролов Г.В. Мультимедиа для Windows, М.: Диалог МИФИ, 1994. – 284 с.
100. Хамов Г.Г. Методическая система обучения алгебре и теории чисел в педвузе с точки зрения профессионально-педагического подхода. СПб.: Рос. гос. пед. ун-т, 1993. – 142 с.
101. Христочевский С.А. Базовые элементы электронных учебников и мультимедийных энциклопедий. Системы и средства информатики. – М.: Наука, 1999. – 298 с.
102. Христочевский С.А. Электронные мультимедийные учебники и энциклопедии // Информатика и образование. – 2000. – № 2. – С.70-77.
103. Что такое HTML5? [Электронный ресурс] // bigfozzy.com : SEO: софт и информация. Терминология, 2015. URL: // http://bigfozzy.com/Articles/Based/Terminology/whotis_html5.php (дата обращения: 12.04.2015).
104. Шәмсетдинова Г.Я. Яңа педагогик технологияләр, укыту эшчәнлегенең яңа формалары аша укучыларның коммуникатив компетенциясен күтәрү [Электронный ресурс] // teacher-rt.ru : Интернет-портал учителей РТ, 2014. URL: // http://www.teacher-rt.ru/index.php/biblioteka/tatar-tele/354-tatar_telen_

ukytuda_ja_a_pedagogik_tekhnologijal_r (дата обращения: 10.09.2014)
105. Юзмиева С.Г. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә информацион технологияләрне куллану. Методик семинар [Электронный ресурс] // nsportal.ru: социальная сеть работнико образования, 2015. URL: // http://nsportal.ru/shkola/obshchepedagogicheskie-tekhnologii/library/2015/01/10/tatar-tele-hm-dbiyaty-dreslrend (дата обращения: 12.02.2015)
106. Юсупов Р.М., Заболотский В.П. Научно-методические основы информатизации. СПб.: Наука, 2000. – 455 с.
107. Açılım Türkçe ders kitabı 1 [Электронный ресурс] : электрон. приложение – Izmir : Dilset, 2010. – 1 CD-ROM
108. eba.gov.tr [Электронный ресурс] // eba.gov.tr : социальный портал, 2013. URL: // http://www.eba.gov.tr/ (дата обращения: 7.04.2015).
109. Elektron dərs resurslari [Электронный ресурс] // e-resurs.edu.az: Электронные ресурсы, 2014. URL: // http://www.e-resurs.edu.az/site/index.php (дата обращения: 12.04.2015).
110. e-okul.meb.gov.tr [Электронный ресурс] // e-okul.meb.gov.tr : электронная школа, 2007. URL: // https://e-okul.meb.gov.tr (дата обращения: 12.04.2015).
111. meb.gov.tr [Электронный ресурс] // meb.gov.tr : Министерство образования Турции, 2015. URL: // http://www.meb.gov.tr/meb_haberindex.php?dil=tr (дата обращения: 1.04.2015).
112. Plowman L. Narrative, Linearity and interactivity: making sense of interactive multimedia. // British Journal of Educational Technology – 27 (2) – 1996. – pp. 92-105.
113. WebSoft [Электронный ресурс] // websoft.ru: Лондон: электронные учебники в ближайшие годы получат широкое распространение, 1999-2014. URL://http://www.websoft.ru/db/wb/F1B5BD8B413D0E95C3256CC6005B310D/doc.html (дата обращения: 7.12.2014).
114. Whyepub [Электронный ресурс] // whyepub.ru : всё о формате ep

**ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНӘ
ЭЛЕКТРОН КУШЫМТАЛАР**

**Методик ярдәмлек**

Форм.бум. 60x84 $^{1}/_{16}$. Гарнитура Times New Roman.
Усл.печ.л. 4,25

Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
E-mail: irort2011@gmail.com